**Татарский язык с Г. Тукаем. Поэтические сказки**

**Габдулла Тукай**

**ӘКИЯТЛӘР** ***(сказки)***

Подготовила **Лилия Валиуллина**

*Метод чтения Ильи Франка*

## ШҮРӘЛЕ *(Шурале, Леший)*

### I

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл *(прямо за Казанью есть одна деревня; арт – зад, задняя часть)* —
«Кырлай» диләр *(Кырлай /её/ называют)*;

Җырлаганда көй өчен *(когда поют, для рифмы; җырлау – петь; көй – мелодия, порядок)*, «тавыклары җырлай», диләр *(«/её/ курицы поют, /так/ говорят; тавык – курица)*.
Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем *(хоть там и не родился, я немного пожил; тугъмасам = тумасам, туу – родиться; тору – жить)*;
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем *(землю немножко бороновал,*

*сеял, жал; тырма – боронование; чәчү – сеять; урак – жатва; идем – вспом. глагол, здесь обозначает прошлое многократное действие)*.

Ул авылның, һич онытмыйм, һәрьягы урман иде *(у той деревни, никогда не забуду, с каждой стороны лес был)*,

Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде *(этот луг из зеленых трав бархатным одеялом был)*.

Зурмы, дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә *(большая ли, /если/ спросить, большой не была, эта деревня очень маленькая)*;

Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә *(народом выпиваемая вода очень маленькая – ручеек лишь)*.

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава *(там не очень холодно и не очень жарко, средний климат)*;

Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява *(и ветер вовремя дует, и дождь вовремя льет)*.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк *(в /её/ лесу красная малина и земляника)*;

Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк *(пока моргнешь: «пока глаза открыв, закроешь», несомненно, соберешь одно ведро; ачу – открывать; йому – закрывать /глаза/; җыю – собирать)*.

Бик хозур *(очень весело)*! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат *(рядами стоят, как войско, ели, сосны; рәт – ряд, строй; кеби = кебек – как, подобно)*;

Төпләрендә ятканым бар *(у подножий я лежал: «лежание мое было»; төп – дно, основание)*, хәл җыеп, күккә карап *( с силами собираясь, в небо глядя)*.

Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр *(у подножий лип, берез – щавель, грибы)*

Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр *(вместе растут разноцветные цветы, бутоны)*.

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр *(белые, красные, алые, желтые-прежелтые, синие, зеленые цветы)*;

һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр *(во все стороны приятные ароматы испускают эти цветы)*.

Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп *(сердят цветы разноцветные бабочки, прилетая, улетая, снова туда же приседая; үпкәләү – сердить, обижать; чүгәләү – приседать)*

Бервакыт чут-чут итеп сайрый Ходайның кошлары *(время от времени поют Божьи птички; бервакыт – однажды, когда-нибудь; чут-чут – звукоподражание трели соловья)*;

Китә жаннарны кисеп, ярып садаи хушлары *(летят, души рассекая, разрывая, приятные напевы)*.

Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул *(здесь и бульвары, клуб и танцевальня, цирк тоже это)*;

Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул *(здесь оркестр, и театры это, и концерт это)*.

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби *(большой это лес: границ не видно, как море; чит – граница)*,

Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби *(очень много, бесчисленно, как войско Чингиза; бихисап – бесчисленно)*.

Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре *(внезапно на память приходят имена, державы)*

Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен саулә тләре *(старых дедов, видел бы /ты/, вся отвага)*.

Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе *(открывается перед /тобой/ истории театральный занавес)*:

Аh! дисең, без ник болай соң? без дә Хакның бәндәсе *(ах! скажешь, мы почему так-то? мы тоже Божьи люди)*.

**I**

**Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл—**
**«Кырлай» диләр;**

**Жырлаганда көй өчен, «тавыклары жырлай», диләр.**
**Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем;**

**Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.**

**Ул авылның, һич онытмыйм, һәрьягы урман иде,**

**Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.**

**Зурмы, дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;**

**Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.**

**Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;**

**Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.**

**Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;**

**Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.**

**Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;**

**Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.**

**Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр**

**Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.**

**Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;**

**һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.**

**Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләк-**

**ләр килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.**

**Бервакыт чут-чут итеп сайрый Ходайның кошлары;**

**Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.**

**Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;**

**Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.**

**Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,**

**Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.**

**Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре**

**Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен Сауләтләре.**

**Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе:**

**Аһ! дисең, без ник болай соң? без дә Хакның бәндәсе.**

**II**

Җәй көнен яздым бераз *(летние дни описал немного)*; язмыйм әле кыш, көзләрен *(не буду описывать зиму, осень)*,

Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын *(розовощеких, чернобровых, черноглазых девушек)*.

Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабан туйларын *(этой деревни я гуляния, площадь, сабантуи)*

Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым *(не пишу, боясь, что в дали уйдут /мои/ мысли; ерак – далеко; уй – мысль)*...

Тукта, мин юлын адашканмын икән бит, күр әле *(подожди, я в дороге заблудился ведь, оказывается, посмотри-ка; адашу – запутаться, заблудиться)*,

Әллә ник истән дә чыккан *(не знаю почему из памяти выпало)*, сүз башым бит «Шүрәле» *(название: «начало слова» ведь «Шурале»)*.

Аз гына сабрит әле, әй кариэм! хәзер язам *(немного только потерпи уж, эй, читатель /мой/! сейчас напишу; сабрит = сабыр ит – потерпи; кари/э/ – читатель)*;

Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам *(/если/ подумаю о /своей/ деревне, ума сразу лишаюсь; гакыл = акыл – ум, рассудок; язу – лишаться)*.

**Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,**
**Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.**
**Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын**
**Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым...**
**Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле,**
**Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит «Шүрәле».**
**Аз гына сабрит әле, әй кариэм! хәзер язам;**
**Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.**

**III**

Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар *(известно, в этом черном лесу любой зверь есть)*,

Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар *(есть: «не нет» медведь, волк; лиса – /любая/ земная тварь есть)*.

һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши *(и есть здесь заяц, хомяк, белка, суслик, лось)*,

Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше *(встречает, будучи охотниками, в лесах много бродящий люд; ау – охота)*.

Бик куе булганга *(из-за сильной густоты: «/потому что/ очень густой есть»)*, монда җен-пәриләр бар, диләр *(здесь всякая нечисть есть, говорят; җен – джинн; пәри – пери)*,

Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр *(всякие чудища, ведьмы, шурале есть, говорят)*,

һич гаҗәп юк, булса булыр, — бик калын, бик күп бит ул *(ничего удивительного нет, может быть, – очень густой, очень большой ведь он; күп – много, изрядно)*;

Күктә ни булмас дисең *(в небе чего не будет, скажешь)*, — очсыз-кырыйсыз күк бит ул *(безбрежное небо ведь оно)*!

**Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар,**
**Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.**
**һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши,**
**Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.**
**Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр,**
**Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр,**
**һич гаҗәп юк, булса булыр, — бик калын, бик күп бит ул;**
**Күктә ни булмас дисең, — очсыз-кырыйсыз күк бит ул!**

**IV**

Шул турыдан аз гына — биш-алты сүз сөйлим әле *(об этом немного только – пять-шесть слов скажу-ка)*,

Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле *(по /моей/ привычке немного лишь спою-ка, напою-ка; гадәт – привычка; көйләү – напевать, читать нараспев)*.

Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет *(в очень красивый лунный вечер /из/ этой деревни один парень; җегет = егет – парень)*

Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп *(пошел в лес за дровами, в одиночку, одного коня запряг; җигү – запрягать)*.

Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук *(быстро доехал парень, за работу принялся, сразу как доехал)*

Кисә башлаган утынны балта берлән «тук» та «тук» *(рубить начал дрова топором «тук» да «тук»)*!

Җәйге төннең гадәтенчә, төн бераз салкын икән *(как обычно в летние ночи, ночь немного холодная, оказывается; төн – ночь)*;

Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән *(/потому что/ все птицы спят, лес тихий, оказывается)*.

Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә *(в эту тихую, хорошую погоду наш дровосек же)*,

Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә *(/где/ перед-зад, право-лево не зная, дрова рубит)*.

Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора *(топор в руке, Парень работу немного приостанавливает)*;

Тукта, чү *(подожди, стоп)*! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра *(некрасивым голосом незнамо что кричит)*.

Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә *(вздрогнув, наш Парень застывает, стоя)*,

Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә *(не понимая, перед собой незнамо какое «нечто» видит; ят – чуждое)*.

Нәрсә бу *(что это)*? Качкынмы, җенме *(беглец ли, джинн ли)*? Йә өрәкме, нәрсә бу *(или призрак, что это)*?

Кот очарлык *(душа /готова/ улететь)*, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу *(очень нескладное, незнамо какое нечто это; килешсез – некрасивый, нескладный)*!

Борыны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби *(нос кривущий – согнулся совсем как крючок; бөгелү – сгибаться)*;

Төз түгел куллар, аяклар да — ботак-тармак кеби *(не стройные руки, и ноги – как сучья-ветви)*.

Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре *(блестят, сверкают глубоко посаженные глаза)*,

Кот очар, күрсәң әгәр, төнлә түгел — көндезләре *(душа улетит, если увидишь, не ночью – /даже/ днем)*.

Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе *(совсем голый, очень тонкий, но как человек сам)*;

Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе *(со средний палец длиной есть на лбу рог; буй – длина; маңгай – лоб)*.

Кәкре түгелдер моның бармаклары — бик төз төзен *(не кривые у него пальцы – очень стройные /если говорить о стройности/)*,

Тик килешсез — һәрбере дә ярты аршыннан озын *(но нескладные – каждый по пол-аршина длиной)*.

**Шул турыдан аз гына — биш-алты сүз сөйлим әле,**

**Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.**

**Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет**

**Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.**

**Тиз барып житкән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,**

**Кисә башлаган утынны балта берлән «тук» та «тук»!**

**Җәйге төннең гадәтенчә, төн бераз салкын икән;**

**Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.**

**Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,**

**Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.**

**Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора;**

**Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.**

**Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә,**

**Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.**

**Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?**

**Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!**

**Борыны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;**

**Төз түгел куллар, аяклар да — ботак-тармак кеби.**

**Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,**

**Кот очар, күрсәң әгәр, төнлә түгел — көндезләре.**

**Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;**

**Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.**

**Кәкре түгелдер моның бармаклары — бик төз төзен,**

**Тик килешсез — һәрбере дә ярты аршыннан озын.**

V

Бик озак торгач карашып *(очень долго простояв, переглядываясь)*, күзне күзгә ник терәп *(глаза в глаза уставившись; терәү – упирать /глаза/)*,

Эндәшә батыр утынчы *(обращается смельчак-дровосек)*: «Сиңа миннән ни кирәк *(тебе от меня что нужно)*?»

— Бер дә шикләнмә, Җегет, син *(вовсе не тревожься, Парень, ты)*;

мин карак-угъры түгел *(я не грабитель-вор; угъры = угры – вор)*,

Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел *(и дорогу не преграждаю, но при этом я не такой уж положительный; тугъры = тугры – правдивый, преданный)*.

Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм *(/моя/ привычка /такая/: одиноких людей щекоткой убиваю; кытыклау – щекотать)*;

Мин әле, күргәч сине, шатланганымнан үкерәм *(я еще, увидев тебя, от радости завываю; шатлану – радоваться)*.

Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым *(но только щекотать готовы мои пальцы; яралу – зарождаться)*;

Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым *(бывает, наверное, рассмешив, людей убиваю, /такие/ времена; булу – быть, бывать; чак – время)*.

Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и *(иди-ка, и ты немного /свои/ пальцы встряхни; селкетү – шевелить, встряхивать)*

Яшь Җегет *(молодой Парень)*! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети *(иди же, вдвоем поиграем немного в щекотку)*.

— Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, мин карышмый уйныймын *(хорошо, хорошо, и слов нет, я, не упрямясь, поиграю; карышу – упрямиться)*,

Тик сине шартыма күнмәссең диеп мин уйлыймын *(только ты с /моими/ условиями не согласишься, так я думаю; шарт – условие; күнәү – соглашаться)*.

— Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм *(какие условия, рассказывай, эй, несчастный человечек /мой/)*?

Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм *(только побыстрее /давай/ поиграем, пожалуйста, что велишь, с тем соглашусь)*.

— Сөйләем шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә *(рассказываю /свое/ условие тебе, хорошо слушай: вон; тору – здесь вспом. глагол, обозначает длительность действия)*

Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә *(там есть же очень длинное и очень толстое бревно)*.

Мин дә көч-ярдәм бирермен: әйдә, иптәш, кузгалыйк *(и я силу-помощь дам: давай, друг, сдвинем)*,

Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк *(то дерево вместе на эту телегу положим; салу – класть)*.

Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы *(в бревне с одного конца есть раскрытая трещина; ярык – трещина)*,

Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы *(за это место сильно ты держи, эй, лесной баран; җир – место, земля)*!

Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире *(с этим советом и Шурале согласился, не идя наперекор)*,

Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире *(пошел в указанное место, вышагивая: «шагая шаги» широко; атлау – шагать; адым – шаг; ире = эре – крупный)*;

Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын *(положил, растяпа, на треснувшее бревно /свой/ палец)*, —

Кариэм, күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын *(читатель /мой/, увидел ли, наконец, молодого Парня хитрость)*!

Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу *(постукивает топором по зажатому клину; кыстыру – защемлять, зажимать)*,

Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу *(свою хитрость потихоньку приводит в порядок; көй – порядок, система)*.

**Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,**
**Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»**

**— Бер дә шикләнмә, Җегет, син;**
**мин карак-угъры түгел,**

**Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел.**
**Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;**
**Мин әле, күргәч сине, шатланганымнан үкерәм.**
**Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;**
**Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.**
**Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и**
**Яшь Җегет! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети.**

**— Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, мин карышмый уйныймын,**

**Тик сине шартыма күнмәссең диеп мин уйлыймын.**

**— Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?**

**Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.**

**— Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә**

**Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.**

**Мин дә көч-ярдәм бирермен: әйдә, иптәш, кузгалыйк,**

**Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.**

**Бүрәнәнең бер очында бар эчелгән ярыгы,**

**Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!**

**Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире,**

**Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире;**

**Куйды илтеп аузын эчкән бүрәнәгә бармагын, —**

**Кариэм, күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын!**

**Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу,**

**Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.**

Шүрәле тыккан кулын — селкенмидер, кузгалмыйдыр *(Шурале засунул руку – не шевелится, не двигается; тыгу – засовывать; селкенү – шевелиться; кузгалу – двигаться)*;

Белми инсан хәйләсен — һич балтага күз салмыйдыр *(не знает человеческую хитрость – совсем на топор не смотрит: «глаз не кладет»)*.

Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп *(пока стучал, под конец клин выскочил, высвободившись; сугу – стучать; буш – пустой, свободный)*,

Шүрәленең бармагы калды — кысылды шап итеп *(у Шурале палец остался – защемился с треском; шап – звукоподражание шуму)*.

Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра *(почувствовал /это/ дело и Шурале: кричит и орет)*,

Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра *(чувствует боль и на помощь /других/ шурале зовет)*.

Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына *(сейчас уж Шурале нашего Парня умоляет)*,

Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына *(прощения просит за /свои/ дела, на святость рассчитывает)*:

— Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәмгенәм *(ты немного пожалей меня, спаситель, эх, человек; кызгану – жалеть)*;

Моннан ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм *(после этого тебя, /твоего/ сына, /твой/ род не трону; ул – сын; нәсел – род)*.

Башкалардан да тидермәм, ул минем дустым, диеп *(и остальным не дам тронуть, он мой друг, /так/ сказав; башка – другой; тидерү – понуд. от тию; тию – трогать)*,

Аңа урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп *(ему по лесу ходить я сам велел, /так/ сказав)*.

Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр *(очень болят /мои/ руки, дружок, отпусти, пожалуйста, отпусти)*;

Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар *(от огорчения Шурале что есть тебе, что есть; рәнҗету – огорчать, обижать)*?

Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша *(раскачивается и вырывается, несчастным рассудком обезумевает)*;

Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа *(в это время молодой Парень домой возвращаться собирается)*.

**Шүрәле тыккан кулын — селкенмидер, кузгалмыйдыр;**

**Белми инсан хәйләсен — һич балтага күз салмыйдыр.**

**Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,**

**Шүрәленең бармагы калды — кысылды шап итеп.**

**Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,**

**Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра.**

**Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына,**

**Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына:**

**— Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәмгенәм;**

**Моннан ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм.**

**Башкалардан да тидермәм, ул минем дустым, диеп,**

**Аңар урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп.**

**Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр;**

**Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?**

**Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша;**

**Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.**

Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә *(коня за голову взял он, этого Шурале и не знает)*;

Ул моның фөрьядларын аслан колакка элми дә *(он к его стенаниям вовсе и не прислушивается: «на ухо не вешает»; фөрьяд = форьяд – стенание, крик о помощи)*

— И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең *(эй, Парень, совсем нет, оказывается, милосердных чувств у тебя; хис – чувство)*;

Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез *(скажи, пожалуйста, безжалостный)*! Кем син *(кто ты)*? Исмең кем синең *(как тебя зовут: «имя кто твое»; исем – имя)*?

Иртәгә килгәнче дустлар, тәндә җаным торса гәр *(завтра к приходу друзей в теле /моя/ душа останется если; гәр = әгәр – если)*,

Шул фәлән атлы кеше кысты диермен сорсалар *(тот с таким-то именем человек зажал скажу, /если/ спросят; ат – имя, название; сорау – спрашивать)*.

— Әйтсәм әйтим, син белеп кал *(скажу так скажу, ты знай: «зная, оставайся»; калу – здесь вспом. глагол, означает результативное действие)*:

чын атым «Былтыр» минем *(настоящее имя «Прошлый год» мое)*.

Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем (этот Парень /твоим/ дядей станет, имей это в виду, братишка; *абзый – дядя, старший по возрасту*)!
Шүрәле фөрьяд итәдер; аудан ычкынмак була (Шурале жалуется; из ловушки высвободиться пытается; *ау – ловушка, охота; ычкыну – высвобождаться*),
һәм дә ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була (и высвободившись, Парню кое-какое дело сделать хочет).
Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз «Былтыр» мине (кричит: «Зажал, ужасное сделал злодей «Прошлый год» мне),
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине (ах, умираю ведь, из этой напасти кто, придя, вытащит меня; *йолку – вырвать, выдернуть*)?»
Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр (наутро /другие/ шурале этого несчастного бранят; *тиргәү – бранить, ругать*)

— Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең (ты ненормальный, ты взбесившийся, ты сумасшедший), — диләр (говорят).

Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел (говорят: «Не кричи ты, быстро подобру прекрати; *тыелу – воздерживаться*)!
И җүләр (эй, ненормальный)! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел (защемившись в прошлом году, кричат разве в этом году)!»

**Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;**
**Ул моның фөрьядларын аслан колакка элми дә.**

**— И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;**
**Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең?**
**Иртәгә килгәнче дустлар, тәндә җаным торса гәр,**
**Шул фәлән атлы кеше кысты диермен сорсалар.**

**— Әйтсәм әйтим, син белеп кал:**
**чын атым «Былтыр» минем.**

**Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!**

**Шүрәле фөрьяд итәдер; аудан ычкынмак була,**

**һәм дә ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була.**

**Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз «Былтыр» мине,**

**Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»**

**Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:**

**— Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең, — диләр.**

**Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!**

**И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел!»**

1907

**СУ АНАСЫ** *(водяная: «мать воды»)*

*(Бер авыл малае авызыннан /из уст одного деревенского мальчика/; авыз – рот)*

I

Җәй көне *(летний день)*. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм *(в жаркую погоду я в воде купаюсь, плаваю; һава – воздух; погода)*;

Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм *(брызгаюсь, играю, ныряю, головой воду бодаю; чәчрәтү – брызгать; уйнау – играть; чуму – нырять; сөзү – бодать)*.

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач *(таким образом около полутора часов поиграв; кадәр – до, вплоть до)*,

Инде, шаять, бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач *(уже, наверное, около часа: «без*

*одного часа» не вспотею, так подумав; сәгать – час; тирләү – потеть)*,

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым *(выбежал из воды, быстро-быстро одел /свою/ одежду; йөгерү – бежать; чыгу – выходить; су – вода; киенү – одеваться)*;
Куркам үзем әллә нидән, — юк янымда юлдашым *(боюсь, сам не знаю чего, – нет рядом попутчика; курку – бояться; ян – в разных значениях бок; боковой)*.

Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага *(в одно время, /когда/ уходить собрался, взглянул: «упал глаз» на мостик; китү – уходить; төшү – падать; спускаться; басма – ступень; мостик)*;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада *(смотрю: одна страшная женщина сидит на мосту; карау – смотреть; утыру – сидеть)*.

Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак *(ярче света: «вопреки свету» сверкает в руке золотой гребень; көн – день; свет; ялтырау – сверкать; кул – рука)*;
Шул тарак берлән утыра тузгыган сачен тарап *(этим гребнем, сидит, растрепанные волосы расчесывая; берлән = белән – с, вместе; сач = чәч – волосы; тарау – расчесывать)*.

**Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;**
**Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.**

**Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,**
**Инде, шаять, бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,**

**Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;**
**Куркам үзем әллә нидән, — юк янымда юлдашым.**

**Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага;**

**Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.**

**Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;**
**Шул тарак берлән утыра тузгыган сачен тарап.**

Тын да алмыйча торам *(не могу вздохнуть: «и дыхание не взяв», стою; алу – брать, взять; тору – стоять)*, куркып кына, тешне кысып *(боясь лишь, зубы стиснув; курку – бояться; теш – зуб; кысу – сжимать, стиснуть)*,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып *(там вдоль берега в густых деревьях прячась; буе – вдоль; агач – дерево; посу – затаиться, спрятаться)*.

Сачләрен үргәч тарап *(/свои/ волосы заплетя, /сначала/ расчесав; үрү – плести)*, сикерде төште суга ул *(спрыгнула, спустилась в воду она; сикерү – прыгать; төшү – спускаться)*;
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул *(нырнула и уплыла, совсем исчезла с глаз там она; чуму – нырять; күз – глаз)*.

Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага *(уж я тихонько подошел и взошел на мост; килү – приходить; керү – заходить, входить)*,
Җен оныткан, ахыры, — калган тарагы басмада *(нечистая забыла, похоже, – остался /её/ гребень на мосту; оныту – забывать; калу – оставаться; тарак – гребень)*.

Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин *(/то, что/ по сторонам /от меня/ никого нет, узнал я; як – сторона; юклык – отсутствие; белү – узнать)*,
Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин *(помчался в деревню, гребень быстро подвесил я; чабу – бежать, мчаться; элү – вешать, подвесить)*.

Күрмимен алны вә артны *(не вижу /ни/ впереди, /ни/ сзади; күрү – видеть; ал – перед; арт – задняя часть)*, и чабам мин, и чабам *(и бегу я, и бегу)*;

Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам *(тороплюсь, потею, парюсь и горячо, как огонь, горю; ашыгу – торопиться; пешү – упариваться; ут – огонь; яну – гореть)*.

**Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,**
**Шунда яр буендагы куе агачларга посып.**

**Сачләрен үргәч тарап, сикерде төште суга ул;**
**Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.**

**Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага,**
**Җен оныткан, ахыры, — калган тарагы басмада.**

**Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,**
**Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.**

**Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;**
**Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.**

Берзаманны әйләнеп баккан идем артка таба *(в одно время, оглянувшись, посмотрел назад; әйләнү – поворачиваться; баку = карау – смотреть)*, — Аһ, харап эш *(ах, страшное дело)*! — Су анасы да минем арттан чаба *(водяная тоже за мной бежит)*.

Кычкырадыр: «Качма! качма! Тукта! тукта, и карак! *(кричит: «Не убегай! Остановись, вор!; кычкыру – кричать; качу – убегать; туктау – остановиться)* Ник аласың син аны, — ул бит минем алтын тарак! *(зачем берешь ты его, – это ведь мой золотой гребень)*»

Мин качамын — ул куадыр, ул куадыр — мин качам *(я бегу – она преследует, она преследует – я бегу; куу – преследовать)*;

Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк, ичмасам *(настолько край тихий, нет никого даже; ичмасам – даже /и/)*.

Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт *(таким образом добежали /мы/ до деревни в один момент; чабышу – бежать, состязаться в беге; җитү – достигать)*,
Су анасыны куарга күтәрелде барча эт *(водяную преследовать принялись все собаки; күтәрелү – подниматься)*!

«Вау!» да «вау!» да, «һау!» да «һау!» *(«вау» и «вау», «хау» и «хау»)* –
бертуктамый этләр өрә *(беспрестанно собаки лают; өрү – лаять)*;
Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә *(водяная, испугавшись собак, обратно побежала)*.

**Берзаманны әйләнеп баккан идем артка таба, —**
**Аh, харап эш! — Су анасы да минем арттан чаба.**

**Кычкырадыр: «Качма! качма! Тукта! тукта, и карак!**
**Ник аласың син аны, — ул бит минем алтын тарак!»**

**Мин качамын — ул куадыр, ул куадыр — мин качам;**
**Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк, ичмасам.**

**Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт,**
**Су анасыны куарга күтәрелде барча эт!**

**«Вау!» да «вау!» да, «һау!» да «һау!» —**
**бертуктамый этләр өрә;**
**Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә.**

Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем *(теперь дело уладилось, от страха успокоился, /так/ подумал; җайлану – улаживаться; курку – страх; тынычлану – успокоиться)*;
И явыз карчык *(вот злая старуха)*! тарагыңнан коры калдың, дидем *(без гребня: «от гребня пустой» осталась, /так/ подумал)*.

Өйгә кайттым да *(домой вернулся и; өй – дом; кайту – вернуться)*: «Әни, алтын тарак таптым *(мама, золотой гребень нашёл)*!» — дидем *(сказал)*;
«Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым *(пить хочу, устал, мама, я очень долго бежал; сусау – жажда; ару – устать)*», — дидем *(сказал)*.

Сөйләгәчтен кыйссаны *(после моего рассказа: «/после того, как/ рассказал рассказ»; сөйләү – рассказывать; кыйсса – рассказ)*, алды тарагымны әни *(взяла /мой/ гребень мама)*;
Курка үзе алса да *(боится сама, хоть и взяла)*, — уйлый эченнән әллә ни *(думает про себя: «изнутри» о чем-то)*...

**Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем;**
**И явыз карчык! тарагыңнан коры калдың, дидем.**

**Өйгә кайттым да: «Әни, алтын тарак таптым!» — дидем;**
**«Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым», — дидем.**

**Сөйләгәчтен кыйссаны, алды тарагымны әни;**
**Курка үзе алса да, — уйлый эченнән әллә ни...**

II

Яхшы, хуш *(ладно, хорошо)*. Батты кояш *(зашло солнце; бату – тонуть; зайти, закатиться /о солнце/)*. Йокларга яттым кич белән *(спать лег вечером; йоклау –*

*спать; яту – ложиться)*;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән *(дом полон был вечерним воздухом, приятными ароматами; эч – живот, нутро; тулу – наполняться)*.

Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман *(под одеялом, не засыпая: «в сон не уходя», лежу я всё; йокы – сон)*;
Шык та шык! — кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман *(тук да тук – кто-то в окно постукивает в один момент; чиертү – щёлкать, постукивать)*.

Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да кузгалмыйм әле *(я лежу хорошо так, не встаю и не двигаюсь даже; тору – вставать; кузгалу – шевелиться)*.
Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни *(от этого шума вздрогнув, проснулась: «встала со сна» мама; тавыш – звук, шум; сискәнү – вздрагивать от шума)*:

— Ни кирәк *(что нужно)*? Кем бу *(кто это)*? Кара төндә вакытсыз кем йөри *(темной ночью не вовремя кто ходит; вакыт – время)*?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери *(что есть-то ночью, черт возьми: «/мой/ нож вонзился бы»; пычак – нож; пычагым – ни черта; керү – входить)*

— Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак *(водяная я, принеси, где мой золотой гребень; китерү – приносить)*?
Бир! бая көндез алып качты синең угълың, карак *(дай! давеча днем, стащив, сбежал твой сын, вор)*

**Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;**
**Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.**

**Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;**
**Шык та шык! — кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.**

**Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да кузгалмыйм әле.**

**Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни:**

**— Ни кирәк? Кем бу? Кара тәндә вакытсыз кем йөри?**

**Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери!**

**— Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?**

**Бир! бая көндез алып качты синең угълың, карак!**

Төшкән айның шәүләсе *(упал лунный свет; төшү – падать; спускаться; шәүлә – отсвет, блик)*, мин юрган астыннан карыйм *(я из-под одеяла смотрю)*;

Калтырыйм, куркам *(дрожу, боюсь; калтырау – дрожать)*:

«Ходай! — дим, — инде мин кайда барыйм?» *(Боже, думаю, уж мне куда идти; бару – идти)*

һич өзлексез шык та шык *(только беспрерывно тук да тук)*! безнең тәрәзәне кага *(в наше окно стучит; кагу – стучать)*;

Ул коточкыч сачләреннән чишмә төсле су ага *(с этих ужасных волос роднику подобно вода течет)*.

Әнкәем алтын таракны, тиз генә эзләп табып *(мамочка /моя/ золотой гребень, быстренько отыскав; эзләү – искать; табу – находить)*,

Атты да тышка, тизүк куйды тәрәзәне ябып *(выбросила на улицу, быстро окно закрыв; ябу – закрыть; кую – здесь вспом. глагол, означает результативное действие)*.

Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни *(от водяной избавившись, успокоившись, мама; котылу – избавиться; тынычлану – успокоиться)*

И орышты, и орышты, и орышты соң мине *(и ругала, и ругала, и ругала же меня;*

*орышу – ругать)*!

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым *(я тоже с тех пор на такие дела не отваживался; кыю – сметь; башлау – начать)*,
«Йә иясе юк *(/их/ хозяина нет)*!» — дип, әйберләргә тими башладым *(так /чужие/ вещи трогать перестал: «вещи не трогать начал»; әйбер – вещь; тию – трогать)*.

**Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм;**
**Калтырыйм, куркам:**

**«Ходай! — дим, — инде мин кайда барыйм?»**

**Һич өзлексез шык та шык! безнең тәрәзәне кага;**
**Ул коточкыч сачләреннән чишмә төсле су ага.**

**Әнкәем алтын таракны, тиз генә эзләп табып,**
**Атты да тышка, тизүк куйды тәрәзәне ябып.**

**Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни**
**И орышты, и орышты, и орышты соң мине!**

**Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,**
**«Йә иясе юк!» — дип, әйберләргә тими башладым.**

1908

**КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК ХИКӘЯСЕ** ***(рассказ о Козле и Баране)***

Борын заман бер Ир белән Хатын торган *(в древние времена один Мужчина с Женщиной жили; тору – жить; стоять)*,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган *(/их/ жизнь довольно-таки бедной была; тормыш – жизнь)*;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык *(содержали одного Козла и одного Барана; асрау – содержать)*, —
Болар булган берсеннән дә берсе арык *(они были один другого худее)*.

Әйтә бер көн Ире *(говорит в один день Муж)*: «Кара монда, Хатын *(смотри сюда, Жена)*! —
Үзең яхшы беләсең бит печән хакын *(сама хорошо знаешь ведь на сено цену; белү – знать)*, —
Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык *(пусть уйдут от нас Козел и Баран; китү – уходить; чыгу – выходить)*,
Ашап ята бушка гына алар азык *(едят впустую лишь они еду; ашау – есть; яту – здесь вспом. глагол, означает длительность, обычность, постоянство действия)*».

Хатын күнде, диде: «Ирем, ярар, ярар *(Жена уступила, сказала: «Муженек, ладно, ладно; күнәү – уступать)*,
Бу икене кумаклыкка булсын карар *(этих двоих выгоним: «выгнать /пусть/ будет решение»; куу – гнать)*;
Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән *(Козел с Бараном сейчас /пусть/ уйдут от нас)*,
Аларны соң асрап торып ни файда бар *(их уж содержать какой прок есть; тору – вспом. глагол, здесь обозначает повторяемость, длительность и регулярность действия)*?»

Нишли инде мискин Кәҗә белән Сарык *(что делают уж несчастные Козел и Баран; нишләү – что делать; мискин = мескен – несчастный, горемычный)*?
Булмый хуҗа кушканына каршы барып *(нельзя хозяйскому повелению

*противостоять; булу – здесь обозначает форму возможности; кушу – велеть; каршы бару – против идти)*.

Икесенә бер зур гына капчык тегеп *(на двоих один большой мешок приладив; тегү – тачать, зашить)*,

Китте болар кырга таба сәфәр чыгып *(пошли они в поле путешествовать; таба – по направлению к…, сәфәр – путешествие; чыгу – выйти)*.

Китте болар *(пошли они)*. Бара, һаман бара, бара *(идут, всё идут, идут)*, —

Күренмидер күзләренә ак һәм кара *(не различается: «не виднеется глазам», /наверное/, белое и черное; күз – глаз; күренү – видненься, ощущаться)*.

Бара болар *(идут они)*. Күпме баргач, Алла белә *(сколько пройдя, Аллах знает)*,

Юл өстендә үлгән Бүре башын таба *(на дороге мертвого Волка голову находят; өстә – наверху)*.

**Борын заман бер Ир белән Хатын торган,**
**Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;**
**Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык, -**
**Болар булган берсеннән дә берсе арык.**

**Әйтә бер көн Ире: «Кара монда, Хатын! —**
**Үзең яхшы беләсең бит печән хакын, —**
**Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,**
**Ашап ята бушка гына алар азык».**

**Хатын күнде, диде: «Ирем, ярар, ярар,**
**Бу икене кумаклыкка булсын карар;**
**Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән,**
**Аларны соң асрап торып ни файда бар?»**

**Нишли инде мискин Кәҗә белән Сарык?**

**Булмый хуҗа кушканына каршы барып.**

**Икесенә бер зур гына капчык тегеп,**

**Китте болар кырга таба сәфәр чыгып.**

**Китте болар. Бара, һаман бара, бара, —**

**Күренмидер күзләренә ак һәм кара.**

**Бара болар. Күпме баргач, Алла белә,**

**Юл өстендә үлгән Бүре башын таба.**

Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак *(боится голову пошевелить Козел-трусишка; кузгату – пошевелить, сдвинуть)*,

Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак *(давно уж с трусостью Баран един: «общий»)*, —

Баш янында болар икәү тора куркып *(рядом с головой они вдвоём стоят, боясь)*,

Әйтешәләр бер-берсенә: «Син тот, мин тот *(пререкаются друг с другом: «Ты держи, я держи)*!»

Кәҗә әйтә *(Козел говорит)*: «Сарык абзый, син көчлерәк *(дядя Баран, ты сильнее; көчле – сильный)*».

Сарык әйтә *(Баран говорит)*: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк *(ты, бородач, храбрее; гайрәтле – храбрый, отважный)*».

Бүре башын кулга тотып кузгатырга *(Волчью голову, в руки взяв, сдвинуть)*

Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк *(у спутников ни у одного не хватает смелости: «сердца»; юлдаш – спутник, попутчик)*.

Озак торгач шунда Кәҗә белән Сарык *(долго простояв там, Козел и Баран)*,

Бүре башын тоталмыйча *(Волчью голову не сумев взять; тоту – взять, брать; алу – мочь)*, куллар барып *(руками потянувшись: «пойдя»)*,

Башны икәү тотып ике колагыннан *(голову вдвоем схватив за два уха; колак – ухо)*,

Юнәлделәр, капчыклары эченә салып *(направились /дальше/, внутрь мешка*

*положив; юнәлү – направляться, взять курс)*.

Бара болар *(идут они)*. Тукталмастан һаман бара *(безостановочно всё идут)*.
Күрә болар: ерак түгел бер ут яна *(видят они: недалеко один огонь горит)*.
Утны күргәч, иптәшенә әйтә Сарык *(огонь увидев, товарищу говорит Баран)*:
«Әйдә, Кәҗә, куныйк бүген шунда барып *(давай, Баран, заночуем сегодня там: «туда дойдя»; куну – ночевать)*.

Ут янына бүреләр дә килалмаслар *(к огню и волки не смогут подойти; килү – приходить; алу – мочь)*,
Безнең анда кунганлыкны белалмаслар *(о нашем тамошнем ночлеге не узнают; белү – знать; алу – мочь)*».
Сарыкның бу киңәшенә Кәҗә күнде *(с таким советом Барана Козел согласился; күнәү – соглашаться, уступать)*:
«Әйдә, иптәш, ярар, барсак барыйк инде *(давай, друг, ладно, тогда пошли: «если пойдем, пошли»)*».

**Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак,**
**Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак, —**
**Баш янында болар икәү тора куркып,**
**Әйтешәләр бер-берсенә: «Син тот, мин тот!»**

**Кәҗә әйтә: «Сарык абзый, син көчлерәк».**
**Сарык әйтә: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк».**
**Бүре башын кулга тотып кузгатырга**
**Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк.**

**Озак торгач шунда Кәҗә белән Сарык,**
**Бүре башын тоталмыйча, куллар барып,**
**Башны икәү тотып ике колагыннан,**
**Юнәлделәр, капчыклары эченә салып.**

**Бара болар. Тукталмастан һаман бара.**

**Күрә болар: ерак түгел бер ут яна.**

**Утны күргәч, иптәшенә әйтә Сарык:**

**«Әйдә, Кәҗә, куныйк бүген шунда барып.**

**Ут янына бүреләр дә килалмаслар,**

**Безнең анда кунганлыкны белалмаслар».**

**Сарыкның бу киңәшенә Кәҗә күнде:**

**«Әйдә, иптәш, ярар, барсак барыйк инде».**

Кәҗә, Сарык ут янына якын барса *(Козел, Баран к огню /как/ подошли)*,

Мискиннәрнең күз алдында менә нәрсә *(у несчастных перед глазами вот что)*:

Өч-дүрт Бүре утырганнар каршы утка *(три-четыре Волка уселись напротив огня)*,

Тыршып-тыршып пешермәктә алар бутка *(стараясь-стараясь, варят они кашу; тыршып = тырышып – стараясь; пешерү – варить)*.

Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны *(Козел, Баран, увидев такое зрелище)*,

Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны *(осталось от испуга у каждого по половине души)*.

«Исәнмесез, дустлар, Бүре әфәнделәр *(здравствуйте, друзья, господа Волки)*!» —

Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле *(говорят они, не показывая испуг: «испуга состояние»)*.

Куаналар өч-дүрт Бүре, моны күргәч *(радуются три-четыре Волка, это увидев)*,

Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч *(к ним Баран и Козел /раз/ пришли)*:

«Ашыйбыз, — дип, — бу икәвен тотабыз да *(съедим, – говоря, – этих двоих поймаем)*,

Менә ничек ит таптык, — дип, — буткабызга *(вот как мясо нашли, – говоря, – в /нашу/ кашу)*!»

Кәҗә әйтә *(Козел говорит)*: «Кайгырмагыз, бездә ит күп *(не переживайте, у нас мяса много; кайгыру – переживать, печалиться)*;

Ул ит берлән һәркайсыбыз булырбыз тук *(этим мясом каждый /из нас/ будет сыт; берлән = белән – с, вместе)*!

Ни карыйсың *(что смотришь)*? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык *(быстрее будь уж, быстрее будь, Баран)*!

Капчыктагы Бүре башын китер алып *(из мешка Волчью голову доставай; китерү – приносить, доставлять; алу – брать)*!»

Сарык шунда капчыктагы башны ала *(Баран там из мешка голову берет)*, —

Барча Бүре куркуыннан шашып кала *(все Волки от страха обезумевают; шашу – обезуметь; калу – вспом. глагол, здесь обозначает результативное действие)*;

Өч-дүрт Бүре хәйран калып торган чакта *(пока три-четыре Волка в удивлении оставались; чакта – когда, во время)*,

Кәҗә һаман гайрәт чәчә, ачулана *(Козел всё мужеством брызжет, ругается; чәчү – сеять, рассыпать)*.

**Кәҗә, Сарык ут янына якын барса,**

**Мискиннәрнең күз алдында менә нәрсә:**

**Өч-дүрт Бүре утырганнар каршы утка,**

**Тыршып-тыршып пешермәктә алар бутка.**

**Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны,**

**Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны.**

**«Исәнмесез, дустлар, Бүре әфәнделәр!» —**

**Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле.**

**Куаналар өч-дүрт Бүре, моны күргәч,**

**Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч:**

**«Ашыйбыз, — дип, — бу икәвен тотабыз да,**

**Менә ничек ит таптык, — дип, — буткабызга!»**

**Кәҗә әйтә: «Кайгырмагыз, бездә ит күп;**

**Ул ит берлән һәркайсыбыз булырбыз тук!**

**Ни карыйсың? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык!**

**Капчыктагы Бүре башын китер алып!»**

**Сарык шунда капчыктагы башны ала, —**

**Барча Бүре куркуыннан шашып кала;**

**Өч-дүрт Бүре хәйран калып торган чакта,**

**Кәҗә һаман гайрәт чәчә, ачулана.**

Кәҗә әйтә *(Козел говорит)*: «Микикики! микикики!

Капчыктагы Бүре башы бит уники *(в мешке Волчьих голов ведь двенадцать; уники = унике – двенадцать)*!

Ах, уңмаган, җүләр Сарык, надан Сарык *(ах, бестолковый, глупый Баран, недоумок Баран)*,

Моннан зуррак Бүре башын китер табып *(этой побольше Волчью голову найди; китерү – приносить; табу – находить)*!»

Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны *(Баран тоже быстро понимает этого лгуна; аңлау – понимать; алу – вспом. глагол, здесь обозначает завершение, результат действия)*,

Капчыктан ул алып килә шул ук башны *(из мешка он, достав, приносит ту же голову)*.

Өч-дүрт Бүре чынлап инде куркыштылар *(три-четыре Волка по-настоящему уже испугались)*,

Бер-берсенә күзләрене йөртештеләр *(друг на друга /свои/ глаза переводят)*.

Түгел хәзер Бүреләргә ашау кайгы *(нет сейчас у Волков заботы о еде; ашау – есть)*,

Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы *(быстро-быстро только это место

*покинуть – /такая/ забота)*.

«Ничек качыйк *(как сбежим)*? Ничек табыйк качу юлын *(как найдем путь /чтобы/ убежать)*?» —

һәрбер Бүре шуңар салган бөтен уен *(каждый Волк этому отдал все /свои/ мысли; уй – мысль)*.

Торып әйтә шул арада өлкән Бүре *(встав, говорит в этот момент старший Волк)*, —

Картайган һәм күп эшләрне үткән Бүре *(постаревший и много дел повидавший Волк)*:

«Туктагыз, — ди, — мин тиз генә су китерим *(подождите, – говорит, я быстренько воду принесу)*,

Суы бик аз, безнең бутка пешәр коры *(воды очень мало, наша каша сварится сухой)*».

Шулай итеп, өлкән Бүре суга китә *(так сделав, старший Волк за водой уходит)*.

Кайтмый ләкин, озак кына заман үтә *(но не возвращается, много уже времени проходит)*.

Кайтмый Бүре — эзе дә юк, исе дә юк *(не возвращается Волк – ни следа, ни запаха)*,

Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә *(сидящий народ устает, ожидая; мәҗлес – собрание; ару – уставать; бетү – вспом. глагол, здесь обозначает полноту, завершенность действия)*.

**Кәҗә әйтә: «Микикики! микикики!**

**Капчыктагы Бүре башы бит уники!**

**Ах, уңмаган, җүләр Сарык, надан Сарык,**

**Моннан зуррак Бүре башын китер табып!»**

**Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,**

**Капчыктан ул алып килә шул ук башны.**

**Өч-дүрт Бүре чынлап инде куркыштылар,**

**Бер-берсенә күзләрене йөртештеләр.**

**Түгел хәзер Бүреләргә ашау кайгы,**

**Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы.**

**«Ничек качыйк? Ничек табыйк качу юлын?» —**

**һәрбер Бүре шуңар салган бөтен уен.**

**Торып әйтә шул арада өлкән Бүре, —**

**Картайган һәм күп эшләрне үткән Бүре:**

**«Туктагыз, — ди, — мин тиз генә су китерим,**

**Суы бик аз, безнең бутка пешәр коры».**

**Шулай итеп, өлкән Бүре суга китә.**

**Кайтмый ләкин, озак кына заман үтә.**

**Кайтмый Бүре — эзе дә юк, исе дә юк,**

**Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә.**

Бүреләрне тагы каты курку басты *(Волков снова сильный страх обуял)*,

Чөнки хәзер башлыклары китеп качты *(потому что сейчас /их/ главарь сбежал; башлык – главарь)*.

Тагын берсе суга таба китте торып *(ещё один за водой пошел, встав)*:

«Туктагыз, мин эзләп кайтыйм *(подождите, я, поискав, вернусь)*», — дигән булып *(так сказав)*.

Мәгълүм инде, бу Бүре дә кача шулай *(известно уж, и этот Волк сбежал так)*,

Хәйлә берлән качарга юл ача шулай *(хитростью бежать дорогу открывает так)*.

Кайтмый бу да, әллә ничә сәгать үтә *(не возвращается и он, не знаю сколько часов проходит)*,

Мәҗлес халкы көтә һаман, көтә, көтә *(сидящий народ ждет всё, ждет, ждет)*.

Өч-дүрт Бүре берсе соңра кача берсе *(три-четыре Волка один за другим сбегают)*,

Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе *(третий, за ним четвертый)*.

Болар качкач, Кәҗә белән безнең Сарык *(после их побега Козел и Баран)*

Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып *(начинают уж блаженствовать, свободу получив)*.

Утыралар аяк бөкләп каршы утка *(садятся, ноги сложив, напротив огня)*,

Болар инде тәмләп кенә ашый бутка *(они уж с аппетитом едят кашу)*.

Ашап туеп, рәхәт кенә, тыныч кына *(наевшись, довольно хорошо, довольно спокойно; кына – лишь, довольно)*

Кәҗә, Сарык бу төннәрен шунда куна *(Козел, Баран этой ночью там ночуют)*.

Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук *(утром рано встав, на рассвете уже)*, —

Кулларында Бүре башы салган капчык *(в руках мешок с Волчьей головой)*, —

Тагын болар урман буйлап сәфәр итте *(снова они по лесам путешествовать пошли)*.

Нәрсә языйм?.. Хикәям дә шунда бетте *(что напишу? и рассказ /мой/ здесь закончился)*.

**Бүреләрне тагы каты курку басты,**

**Чөнки хәзер башлыклары китеп качты.**

**Тагын берсе суга таба китте торып:**

**«Туктагыз, мин эзләп кайтыйм», — дигән булып.**

**Мәгълүм инде, бу Бүре дә кача шулай,**

**Хәйлә берлән качарга юл ача шулай.**

**Кайтмый бу да, әллә ничә сәгать үтә,**

**Мәҗлес халкы көтә һаман, көтә, көтә.**

**Өч-дүрт Бүре берсе соңра кача берсе,**

**Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе.**

**Болар качкач, Кәҗә белән безнең Сарык**

**Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып.**

**Утыралар аяк бөкләп каршы утка,**

**Болар инде тәмләп кенә ашый бутка.**

**Ашап туеп, рәхәт кенә, тыныч кына**

**Кәҗә, Сарык бу төннәрен шунда куна.**

**Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук, —**

**Кулларында Бүре башы салган капчык, —**

**Тагын болар урман буйлап сәфәр итте.**

**Нәрсә языйм?.. Хикәям дә шунда бетте.**

1910

АЛТЫН ӘТӘЧ *(золотой петушок)*

Пушкинның «Сказка о золотом петушке» нам хикәясеннән алынмыш *(переложение сказки Пушкина под названием «Сказка о золотом петушке»)*

I

Борын, үткән заманнарда, Мәмәт атлы Һират ханы *(в давние, прошедшие времена, хан Герата по имени Мамат)*

Олуг данлыклы хан булган, җиһан халкы аны таный *(великим, знаменитым ханом был, мировой народ его признает; тану – знать, признавать)*

Икән, ягъни бу дөньяда беренче патша дип саный *(оказывается, то есть на этом свете первым царем считает)*,

Мәмәт хан чит халыклардан ала булган олуг дани *(Мамат-хан среди чужих народов имел великую славу; алу – брать, получать; булу – быть)*;

Сугышса, дер дә дер тетрәткән ул бу фани дөньяны *(если сражался, потрясал он этот бренный мир; дер-дер итү – трястись; тетрәү – дрожать)*
Чыгарткан чит халык аузыннан ул күп аһ вә фиганны *(заставлял он чужой народ ахать и плакать: "выводил изо рта чужого народа он много ахов и плача"; авыз – рот; фиган – плач, рыдания)*
Бара торгач, усал эштән тәмам туйган моның җаны *(со временем от злых дел порядком пресытилась его душа)*,
Сакалга ак та кергәч *(в бороде седина /как/ появилась: "в бороду белое как вошло")*, ташлаган артына дөньяны *(бросил назад мир = отвернулся от мирской жизни)*.

Сугышмый башлаган һич *(перестал сражаться совсем: "не сражаться начал совсем")*, күңле кайткан хәл дә азлыктан *(настроение упало, и силы на исходе; азлык – скудость, недостаток)*,
Ходай бер кешедәй, тормаган бер дә намазлыктан *(как Божий человек, не вставал совсем с молитвенного коврика; намазлык – коврик для намаза)*,
Бер ай да үтмәгән, һәр якка ханның хәле фашланган *(и месяца не прошло, во все стороны ханское состояние стало явным; фаш булу – быть явным)*
Тирә-күрше халыкларга: «Һират ханы юашланган!» *(соседским народам: «Гератский хан присмирел!»; юашлану – становиться скромным, присмиреть)*

**I**

**Борын, үткән заманнарда, Мәмәт атлы Һират ханы**
**Олуг данлыклы хан булган, җиһан халкы аны таный**
**Икән, ягъни бу дөньяда беренче патша дип саный,**
**Мәмәт хан чит халыклардан ала булган олуг дани;**

**Сугышса, дер дә дер тетрәткән ул бу фани дөньяны**

**Чыгарткан чит халык аузыннан ул күп аһ вә фиганны**

**Бара торгач, усал эштән тәмам туйган моның җаны,**

**Сакалга ак та кергәч, ташлаган артына дөньяны.**

**Сугышмый башлаган һич, күңле кайткан хәл дә азлыктан,**

**Ходай бер кешедәй, тормаган бер дә намазлыктан,**

**Бер ай да үтмәгән, һәр якка ханның хәле фашланган**

**Тирә-күрше халыкларга: «Һират ханы юашланган!»**

Явызлар, серне белгәч, аңлагач ханга ни булганны *(злодеи, тайну узнав, поняв, с ханом что случилось)*,

Тотынганнар тынычсызларга һәр яктан Мәмәт ханны *(принялись беспокоить с каждой стороны хана Мамата; тотыну – начинать, приниматься; тыныч – спокойно)*.

Мәмәткә дәүләтенең чикләрен сакларга “чит”ләрдән *(Мамату государства границы /чтобы/ беречь от чужаков; чик – граница)*,

Тыныч булмак өчен һәр дүрт тарафлардагы чикләрдән *(для спокойствия границ со всех четырех сторон)*,

Тиеш булган хәзер сансыз, хисапсыз гаскәр асрарга *(должен был сейчас бесчисленную, бессчетную армию содержать; сан – число; хисап – счет)*,

Торалар каршы, дошманны куа йокламый гаскәр дә *(противостоит: “стоит напротив”, врага гонит, не спит армия)*.

Тырышалар, вәләкин барчасына өлгералмыйлар *(стараются, но везде не успевают; барча – всё; өлгерү – успевать; алу – мочь)*,

Тулы дүрт якта дошман, бер сәгать тә тик торалмыйлар *(полно с четырех сторон врагов, ни одного часа спокойно постоять не могут; тору – стоять; алу – мочь)*.

Мәмәт хан гаскәре дошман көтеп торганда мәшрикътән *(/когда/ армия хана Мамата врагов ждет с востока; көтү – ждать; тору – здесь вспом. глагол, обозначает повторяемость, длительность и регулярность действия)*,

Менә килеп чыгалар төн ягыннан яки мәгъриптән *(вот появляются с северной стороны или с запада)*.
Мәмәт хан гаскәре көткәндә таудан йә тигез җирдән *(/когда/ армия хана Мамата ждет с гор или равнины; тигез – ровный, җир – место, земля)*,
Карыйлар: бихисап дошман килеп тә җитте диңгездән *(смотрят: бесчисленное /количество/ врагов прибыло с моря)*.

**Явызлар, серне белгәч, аңлагач ханга ни булганны,**
**Тотынганнар тынычсызларга һәр яктан Мәмәт ханны.**
**Мәмәткә дәүләтенең чикләрен сакларга “чит”ләрдән,**
**Тыныч булмак өчен һәр дүрт тарафлардагы чикләрдән,**

**Тиеш булган хәзер сансыз, хисапсыз гаскәр асрарга,**
**Торалар каршы, дошманны куа йокламый гаскәр дә.**
**Тырышалар, вәләкин барчасына өлгералмыйлар,**
**Тулы дүрт якта дошман, бер сәгать тә тик торалмыйлар.**

**Мәмәт хан гаскәре дошман көтеп торганда мәшрикътән,**
**Менә килеп чыгалар төн ягыннан яки мәгъриптән.**
**Мәмәт хан гаскәре көткәндә таудан йә тигез җирдән,**
**Карыйлар: бихисап дошман килеп тә җитте диңгездән.**

Бу хәлдән нинди рәхәт соң *(в таком положении какой же покой)*? Хан аулакта елап куя *(хан в уединении плачет; елау – плакать; кую – здесь вспом. глагол, означает результативное действие)*,
Таҗын, тәхтен тәмам ташлап качарга да теләп куя *(корону, престол совсем бросив, бежать тоже подумывает: “иногда хочет”; тәхет – трон, престол)*.
Бөтенләй аптырап беткәч, чакырды хан багучыны *(вконец испереживавшись, позвал хан знахаря; аптырау – переживать; бетү – здесь вспом. глагол, обозначает полноту, завершенность действия)*,

Мөнәҗҗим, фалчыны һәм дә хәким исмен тагучыны *(астролога, ворожея и мудреца звания носящего /человека/)*.

Хәкимгә: «И хәким! Мин бик авыр хәлләргә калдым!» – ди *(мудрецу: «Эй, мудрец! Я в очень сложном положении остался!» – говорит)*;
«Йә, күрсәт хикмәтеңне, кыйлчы бер эш, кыйлчы ярдәм», – ди *(«Ну, покажи /свою/ мудрость, сделай какое-нибудь дело, окажи помощь», – говорит; кылу – делать)*.
Хәким бер капчык аузына кулын сала да сызганып *(мудрец в горлышко одного мешка руку засовывает, и от души; сызганып – перен. старательно, от всей души)*,
Куя хан алдына шуннан гаҗәп алтын әтәч алып *(ставит перед ханом, оттуда удивительного золотого петуха достав)*.

Һәм әйтә *(и говорит)*: «Падишаһым! Син котылдың инде бик яхшы *(Падишах /мой/! Ты избавился уже очень хорошо)*,
Гомергә дәүләтеңдә бу әтәч булыр сиңа сакчы *(навеки в /твоей/ державе этот петух будет тебе хранителем)*;
Бу кошны миннән ал, хан, мәсҗетең башына кунаклат *(эту птицу от меня прими, хан, на минарете мечети посели)*!
Югартын син аңар һәр дүрт тарафны да, карат, саклат *(наверху ты его все четыре стороны /заставь/ смотреть, охранять; карату – понуд. от карау; карау – смотреть; саклату – понуд. от саклау; саклау – охранять)*!»

**Бу хәлдән нинди рәхәт соң? Хан аулакта елап куя,**
**Таҗын, тәхтен тәмам ташлап качарга да теләп куя.**
**Бөтенләй аптырап беткәч, чакырды хан багучыны,**
**Мөнәҗҗим, фалчыны һәм дә хәким исмен тагучыны.**

**Хәкимгә: «И хәким! Мин бик авыр хәлләргә калдым!” – ди;**
**“Йә, күрсәт хикмәтеңне, кыйлчы бер эш, кыйлчы ярдәм”, – ди.**

**Хәким бер капчык аузына кулын сала да сызганып,**
**Куя хан алдына шуннан гаҗәп алтын әтәч алып.**

**Һәм әйтә: “Падишаһым! Син котылдың инде бик яхшы,**
**Гомергә дәүләтеңдә бу әтәч булыр сиңа сакчы;**
**Бу кошны миннән ал, хан, мәсҗетең башына кунаклат!**
**Югартын син аңар һәр дүрт тарафны да, карат, саклат!»**

Мәснәви *(двустишия)*

«Булмаса курку сиңа, бу тик торыр *(/если/ не будет страшного для тебя, он тихо посидит)*;
Килсә дошман гаскәре, бу кычкырыр *(/если/ придет вражеская армия, он закричит)*.

Булмаса дошман, кыйлыр шунда карар *(/если/ не будет врага, спокойно посидит; кыйлыр шунда карар = тыныч кына торыр)*;
Булса, борылыр, куркыныч якка карар *(/если/ будет, повернется, в опасную сторону посмотрит)*.

Бер тарафка бакса, дисә: кикрикү *(/если/ в одну сторону посмотрит, скажет: кукареку)*!
Бу борылган якка син гаскәрне ку *(в сторону его поворота армию гони)*!»

Хәкимгә патша ни рәхмәт укырга аптырый инде *(мудреца царь как благодарить не знает = переживает)*:
«Сиңа нәрсә бирим, әйтче *(тебе что дать, скажи)*? Ни сурсаң да, бирермен *(что ни спросишь, дам; сурсаң = сорасаң – спросишь)*», – ди *(говорит)*.

Кызулык берлә патша әйтәдер *(с жаром царь говорит)*: «Синең теләгеңне *(твое желание)*

Мин эшләрмен тәвәккыфсыз, бөтенләй үз теләгемдәй *(я выполню немедленно, совсем как своё)*».

**Мәснәви**

**«Булмаса курку сиңа, бу тик торыр;**
**Килсә дошман гаскәре, бу кычкырыр.**

**Булмаса дошман, кыйлыр шунда карар;**
**Булса, борылыр, куркыныч якка карар.**

**Бер тарафка бакса, дисә: кикрикү!**
**Бу борылган якка син гаскәрне ку!»**

**Хәкимгә патша ни рәхмәт укырга аптырый инде:**
**«Сиңа нәрсә бирим, әйтче? Ни сурсаң да, бирермен», – ди.**

**Кызулык берлә патша әйтәдер: «Синең теләгеңне**
**Мин эшләрмен тәвәккыфсыз, бөтенләй үз теләгемдәй».**

II

Ханның мәсҗете башына бәс алтын этәч кунды *(на минарете ханской мечети, стало быть, золотой петух поселился)*

Карый һәр якны: алны, артны, өсне, асны, уң, сулны *(смотрит каждую сторону: перед, зад, верх, низ, право, лево)*.

Кагынмый һәм чыгармый тын да, һәр якны тыныч күрсә *(не бьет крыльями и не издает ни звука, /если/ каждая сторона спокойна: “спокойной видит”)*.

Уянгандай йокыдан кагынадыр, куркыныч күрсә *(встрепенувшись: «как пробудившись ото сна» бьет крыльями, /если/ опасность увидит)*.

Бәла күргәч тә сайрый, кычкырадыр: «Кикрикүккүк!» – ди *(и беду увидев, поет, кричит : «Кукареку!», – говорит)*;

Әгәр китсә бәла, дәрхаль торадыр тик кенә – туктый *(если уходит беда, тотчас встает тихонько – останавливается)*.

Әтәчнең шөһрәте һәр якка китте, инде фашланды *(слава о петухе во все стороны пошла, уже стала явной)*,

Сугыштан тартты кулны чит халыклар да, юашланды *(от войны отдернули руки и чужие народы, присмирели)*.

Хәзер дошман кешеләргә Мәмәт ханга һөҗүм кайда *(сейчас вражеским людям на хана Мамата нападать где уж)*!

Әтәч бикли аларның юлларын алдан да, арттан да *(петух закрывает их пути и спереди, и сзади; бикләү – запирать)*.

Үтә бер ел тынычлык берлә, үтмәктә икенче ел *(прошел один год в спокойствии, проходит второй год)*,

Аманлык һәр тарафта, исмидер һич куркынычлы җил *(благополучие со всех сторон, не веет совсем опасный ветер)*.

**II**

**Ханның мәсҗете башына бәс алтын әтәч кунды**
**Карый һәр якны: алны, артны, өсне, асны, уң, сулны.**
**Кагынмый һәм чыгармый тын да, һәр якны тыныч күрсә.**
**Уянгандай йокыдан кагынадыр, куркыныч күрсә.**

**Бәла күргәч тә сайрый, кычкырадыр: «Кикрикүккүк!» – ди;**
**Әгәр китсә бәла, дәрхаль торадыр тик кенә – туктый.**
**Әтәчнең шөһрәте һәр якка китте, инде фашланды,**
**Сугыштан тартты кулны чит халыклар да, юашланды.**

**Хәзер дошман кешеләргә Мәмәт ханга һөҗүм кайда!**
**Әтәч бикли аларның юлларын алдан да, арттан да.**

**Үтә бер ел тынычлык берлә, үтмәктә икенче ел,**

**Аманлык һәр тарафта, исмидер һич куркынычлы җил.**

Менә көннәрдә бер хан тора куркып йокысыннан *(вот в один из дней хан просыпается в страхе ото сна; көн – день; йокы – сон)*,

Килә тавыш колагына *(идет голос в ухо)*: «Харап эш *(жуткое дело)*! Беттек, и солтан *(кончились = пропали /мы/, эй, султан)*!»

«Ни булды *(что случилось)*? Нәрсә бар соң *(что есть-то)*?» – дип сорый гаскәр башыннан хан *(спрашивает у воеводы хан; баш – руководитель, глава)*;

«Әтәч кычкырды тагын да, килә бугай явыз дошман *(петух закричал снова, идет, похоже, злой враг)*!»

Һират халкы тәмам куркыштылар, башланды шау-шу да *(народ Герата порядком перепугался, начался шум-гам)*.

Хатыннар, яшь балалар, карт бабайлар төште каушауга *(женщины, маленькие дети, пожилые старики впали в страх; каушау – пугаться)*.

Ышанмый хан, торып хан, мәсҗетенә ул үзе карый *(не верит хан, встав, хан на /свою/ мечеть сам смотрит)*,

Күрә: алтын әтәч борган башыны көнчыгыш сарый *(видит: золотой петух повернул голову в сторону востока; сарый = якка – в сторону)*.

Йөгер тиз *(беги быстро)*! Әйдә башла, и җәяүле гаскәр, атларга *(давай начинай, эй, пехотная армия, шагать)*!

Ашык *(торопись)*! И атлы гаскәр, син дә тиз бул *(эй, конная армия, и ты быстрее будь)*! Атлан атларга *(садись верхом на лошадей; атлану – садиться верхом; ат – лошадь)*!

Шулай хан көнчыгышка бихисап гаскәр рәван кылды *(так хан на восток бессчисленную армию отправил; рәван кылу = җибәрү – отправлять)*,

Олуг углын шуларга баш, беренче пәһлеван кылды *(старшего сына им главным, первым богатырем назначил)*.

**Менә көннәрдә бер хан тора куркып йокысыннан,**

**Килә тавыш колагына: «Харап эш! Беттек, и солтан!»**

**«Ни булды? Нәрсә бар соң?» – дип сорый гаскәр башыннан хан;**

**«Әтәч кычкырды тагын да, килә бугай явыз дошман!»**

**Һират халкы тәмам куркыштылар, башланды шау-шу да.**

**Хатыннар, яшь балалар, карт бабайлар төште каушауга.**

**Ышанмый хан, торып хан, мәсҗетенә ул үзе карый,**

**Күрә: алтын әтәч борган башыны көнчыгыш сарый.**

**Йөгер тиз! Әйдә башла, и җәяүле гаскәр, атларга!**

**Ашык! И атлы гаскәр, син дә тиз бул! Атлан атларга!**

**Шулай хан көнчыгышка бихисап гаскәр рәван кылды,**

**Олуг углын шуларга баш, беренче пәһлеван кылды.**

Әтәч тә тынды, һәм әкрен генә тукталды шаулау да *(и петух умолк, и потихоньку утих шум)*,

Тынычланган кеби булды йөрәкләнгән Мәмәт хан да *(как будто успокоился и приободренный хан Мамат)*.

Үтә бер көн, ике, өч, дүрт, үтә җиде, сигез көн дә *(проходит один день, два, три, четыре, проходят и семь, восемь дней)*;

Сугыш булганмы *(сражение было ли)*? Юкмы *(нет ли)*? Килми гаскәрдән хәбәр бер дә *(не приходит от армии ни единой весточки)*.

Хәбәр юк ханга, беркөнне әтәч тавышлана тагын *(новостей нет для хана, однажды петух шумит снова)*,

Менә тиз-тиз икенче фирка гаскәр сафлана тагын *(вот быстро-быстро вторая часть армии готовится снова; фирка = төркем – группа, часть; сафлану – подготавливать)*.

Итә башлык бу гаскәргә Мәмәт хан кечкенә углын *(делает главой этой армии хан Мамат младшего сына)*:

«Бу гаскәр берлә абзаңны табып кайт, бар, җаным углым *(с этой армией брата найди, иди, душа /моя, сын /мой/; табу – находить; кайту – возвращаться)*!»

Үтә көннәр *(проходят дни)*... Үтә әүвәлгесе төсле сигез көн дә *(проходят как и раньше восемь дней)*;

Ике шаһзадәгә ни булганыннан чыкмыйдыр өн дә *(с двумя ханскими сыновьями что случилось, не выходит и звука = нет никакой весточки; шаһзадә – шахзаде, потомок шаха)*.

Һират халкы тагын шауларга башлады, тагын курыкты *(народ Герата снова шуметь начал, снова испугался)*,

Әтәч тавышлана тагын да: «Кикрикүк!» тә «күк!», «күк!» ди *(петух шумит снова: «Кукареку» говорит)*.

**Әтәч тә тынды, һәм әкрен генә тукталды шаулау да,**
**Тынычланган кеби булды йөрәкләнгән Мәмәт хан да.**
**Үтә бер көн, ике, өч, дүрт, үтә җиде, сигез көн дә;**
**Сугыш булганмы? Юкмы? Килми гаскәрдән хәбәр бер дә.**

**Хәбәр юк ханга, беркөнне әтәч тавышлана тагын,**
**Менә тиз-тиз икенче фирка гаскәр сафлана тагын.**
**Итә башлык бу гаскәргә Мәмәт хан кечкенә углын:**
**«Бу гаскәр берлә абзаңны табып кайт, бар, җаным углым!»**

**Үтә көннәр... Үтә әүвәлгесе төсле сигез көн дә;**
**Ике шаһзадәгә ни булганыннан чыкмыйдыр өн дә.**
**Һират халкы тагын шауларга башлады, тагын курыкты,**
**Әтәч тавышлана тагын да: «Кикрикүк!» тә «күк!», «күк!» ди.**

Мәмәт инде өченче гаскәре берлә үзе китте *(Мамат уже с третьей армией вместе сам пошел)*

Туры мәшрикъ таба *(прямо на восток)*: «Тәңре, үзең ярдәм вә фазыл ит!» – ди *(«Всевышний, сам помощь и милость окажи!» – говорит)*.
Бара көн-төн, һаман ял итми, аслан тынмыйдыр үзе *(идет день-ночь, до сих пор не отдыхает, все еще не успокаивается сам)*;
Ни бар алда *(что есть впереди)*? Чыгармы бер-бер эш, һич белмидер үзе *(выйдет ли какое-нибудь дело, вовсе не знает сам)*.

Биш-алты көн бара, шаһзадәләр дә, гаскәре дә юк *(пять-шесть дней идет, ни сыновей, ни армии нет)*,
Түгелгән кан да юк һич, ичмасам, ат эзләре дә юк *(ни пролитой крови нет совсем, хотя бы, ни лошадиных следов нет)*.
Менә сигезенче таң атканда, хан туктады бер тауга *(вот, на рассвете восьмого дня, хан остановился на одной горе; таң ату – рассветать)*;
Җәелде гаскәр, атлар да ничек бу җиргә туктауга *(разбрелась армия, лошади тоже, как на этой земле остановились; җәелү – растягиваться, распространяться)*.

Күренде хан күзенә тау башында бер кызыл чатыр *(показался ханским глазам на горной вершине один красный шатер)*,
Гаҗәп төсле матур, нинди күңелләрне дә кузгатыр *(поразительно красивый, любую душу затронет)*.
Гаҗәип бик матур сахра, һава тын, җил дә юк бер дә *(поразительно очень красивая природа, воздух тихий, и ветра нет совсем)*;
Җиһан йоклый тавыш-тынсыз, бәрабәр, йоклыйдыр кыр да *(мир спит беззвучно-бесшумно, также спит и край)*.

**Мәмәт инде өченче гаскәре берлә үзе китте**
**Туры мәшрикъ таба: «Тәңре, үзең ярдәм вә фазыл ит!» – ди.**
**Бара көн-төн, һаман ял итми, аслан тынмыйдыр үзе;**
**Ни бар алда? Чыгармы бер-бер эш, һич белмидер үзе.**

**Биш-алты көн бара, шаһзадәләр дә, гаскәре дә юк,**

**Түгелгән кан да юк һич, ичмасам, ат эзләре дә юк.**

**Менә сигезенче таң атканда, хан туктады бер тауга;**

**Җәелде гаскәр, атлар да ничек бу җиргә туктауга.**

**Күренде хан күзенә тау башында бер кызыл чатыр,**

**Гаҗәп төсле матур, нинди күңелләрне дә кузгатыр.**

**Гаҗәип бик матур сахра, һава тын, җил дә юк бер дә;**

**Җиһан һоклый тавыш-тынсыз, бәрабәр, йоклыйдыр кыр да.**

Бу нинди куркыныч *(это что за ужас)*! Чатыр тирәсендә бөтен гаскәр *(вокруг шатра вся армия)*

Үлеп ятыр, булып тау-тау, кырылганнар, изелгәннәр *(погибшая лежит, горками, посеклись, передавились)*.

Мәмәт хан, ашыгып, тиз-тиз чатырның алдына бара *(хан Мамат, торопясь, быстро-быстро к шатру идет)*,

Ни күзләр берлә күрсен *(какими глазами /пусть/ увидит)*! Аһлар ормыйча чыдап кара *(не ахнув, вытерпеть попробуй; чыдау – терпеть)*:

Үлеп ятмыш ике шаһзадә, бакый йортка күчкәннәр *(мертвые лежат два сына, в вечности дом переселились; бакый =мәңгелек – вечность)*,

Бере күкрәгенә берсе кылычларын чәнечкәннәр *(друг другу в грудь /свои/ мечи вонзили; кылыч – меч; чәнчү – колоть)*.

Күрә шаһзадәләр атландыгы юрга җирәннәрне *(видит рыжих иноходцев, которых седлали сыновья; атлану – садиться верхом; җирән – рыжий)*,

Йөриләр чүпләнеп әкрен генә канлы чирәмнәрне *(ходят, пожевывая потихоньку окровавленную траву)*.

Елый хан кычкырып: «И җаннарым! И каһреманнарым *(плачет хан в голос: “Эх, души /мои/! Эх, герои /мои/”)*,

Җаным сөйгән ике шаһзадәм, и рухым, рәваннарым *(душою любимые два сына, эх души /мои/; рух – душа; рәван = җан – душа)*!»

Хан артыннан еларга башладылар җөмлә гаскәр дә *(за ханом плакать начала и вся армия)*,

Елый һәрнәрсә, һәркем – җанлы-җансыз барчасы бергә *(плачет всё, каждый – живые-неживые все вместе)*.

**Бу нинди куркыныч! Чатыр тирәсендә бөтен гаскәр**
**Үлеп ятыр, булып тау-тау, кырылганнар, изелгәннәр.**
**Мәмәт хан, ашыгып, тиз-тиз чатырның алдына бара,**
**Ни күзләр берлә күрсен! Аһлар ормыйча чыдап кара:**

**Үлеп ятмыш ике шаһзадә, бакый йортка күчкәннәр,**
**Бере күкрәгенә берсе кылычларын чәнечкәннәр.**
**Күрә шаһзадәләр атландыгы юрга җирәннәрне,**
**Йөриләр чүпләнеп әкрен генә канлы чирәмнәрне.**

**Елый хан кычкырып: «И җаннарым! И каһреманнарым,**
**Җаным сөйгән ике шаһзадәм, и рухым, рәваннарым!»**
**Хан артыннан еларга башладылар җөмлә гаскәр дә,**
**Елый һәрнәрсә, һәркем – җанлы-җансыз барчасы бергә.**

Исеркәп ушбу хәлне кычкырып еглый хәҗәрләр дә *(почувствовав такое положение, в голос плачут и камни; хәҗәр = таш – камень)*,

Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә *(поникли, головы склонили, согнулись и деревья; шәҗәр = агач – дерево)*.

Шулай торганда, аңсыздан чатыр нурга тулып китте *(/пока/ так стояли, неожиданно шатер сиянием наполнился)*,

Мәмәт хан каршысына бик матур бер кыз килеп чыкты *(навстречу хану Мамату очень красивая девушка вышла)*.

Көлеп, як-якка айдай нур йөзеннән яктылык сачып *(смеясь, вокруг подобного лунному сиянию лица свет рассыпая)*,
Кочаклап алды ханны, бер фәрештәдәй канат ачып *(обняла хана, как ангел крылья раскрыв; кочаклау – обнимать; алу – здесь вспом. глагол, обозначает совершение действия в короткий промежуток времени)*.
Тора хан кыз күзе алдында куркынган поши төсле *(стоит хан перед глазами девушки как напуганный лось)*,
Кояш алдында тын алмыйча каткан төн кошы төсле *(как на солнце без дыхания застывшая ночная птица; тын – дыхание; алу – мочь; кату – застыть)*

Хан алдында фида булды хәзер һәркем дә, һәрни дә *(перед ханом жертвой стал сейчас каждый, всё)*,
Гашыйклыктан онытты ул үлек шаһзадәләрне дә *(от любви забыл он и мертвых сыновей)*.
Матур кыз ханны кулыннан тотып кергезде чатырга *(красивая девушка, хана за руку взяв, завела в шатер)*,
Җәюледер мамык мендәр, түшәкләр анда ятырга *(расстелены пуховые подушки, перины там лежат)*.

**Исеркәп ушбу хәлне кычкырып еглый хәҗәрләр дә,**
**Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә.**
**Шулай торганда, аңсыздан чатыр нурга тулып китте,**
**Мәмәт хан каршысына бик матур бер кыз килеп чыкты.**

**Көлеп, як-якка айдай нур йөзеннән яктылык сачып,**
**Кочаклап алды ханны, бер фәрештәдәй канат ачып.**
**Тора хан кыз күзе алдында куркынган поши төсле,**
**Кояш алдында тын алмыйча каткан төн кошы төсле.**

**Хан алдында фида булды хәзер һәркем дә, һәрни дә,**
**Гашыйклыктан онытты ул үлек шаһзадәләрне дә.**

**Матур кыз ханны кулыннан тотып кергезде чатырга,**

**Җәюледер мамык мендәр, түшәкләр анда ятырга.**

Тулы һәртөрле нигъмәт, ялтырыйдыр алтын өстәлләр *(полно всяческих яств, сверкают золотые столы)*,

Чәчәк атып торалар *(расцветают; чәчәк ату – цвести; тору – здесь вспом. глагол, обозначает повторяемость, длительность и регулярность действия)*, төрле-төрле гөлләр үскәннәр *(различные цветы выросли)*.

Кытай кясәләрендә ак, кызыл төсле шәраблар бар *(в китайских чашах белого, красного цвета вина есть)*,

Терел, эч тә күңел ач, анда һәр абел-хәятлар бар *(выздоравливай, пей и настроение поднимай, там любая живая вода есть; абел-хәят – вода вечности)*.

Матур кыз берлә вакты бик матур кичә хәзер ханның *(с красивой девушкой вместе время очень красиво проходит сейчас у хана)*,

Матур кыз кичә, көндез дә кирәгенә хәзер ханның *(красивая девушка и вечером, и днем нужна сейчас хану)*.

Сыйлый кыз һәм сөя, һәртөрле назлар күрсәтә ханга *(угощает девушка и любит, всяческие ласки показывает хану)*,

Сихерләнгән, тәмам гашыйк булып беткән Мәмәт ханда *(околдован, вконец влюбился хан Мамат; гашыйк булу – влюбиться; бетү – здесь вспом. глагол, обозначает полноту, завершенность действия)*.

Бу кыз берлә көлеп уйнап, тәмам атна кадәр торгач *(с этой девушкой смеясь, играя, наконец, почти неделю прожив)*,

Күңел ачкач, зәвыклангач вә күп рәхәт, сафа сөргәч *(настроение подняв, насладившись и много блаженства, удовольствия получив)*,

Мәмәт хан кайта инде яшь бикә берлә Һиратына *(хан Мамат возвращается уже с молодой госпожой в Герат)*,

Ияртеп гаскәрен, саф-саф тезеп һәр дүрт җиһатына *(ведя /с собой/ армию, рядами выстроив с каждой из четырех сторон; җиһат = як – сторона)*.

**Тулы һәртөрле нигъмәт, ялтырыйдыр алтын өстәлләр,**

**Чәчәк атып торалар, төрле-төрле гөлләр үскәннәр.**

**Кытай кясәләрендә ак, кызыл төсле шәраблар бар,**

**Терел, эч тә күңел ач, анда һәр абел-хәятлар бар.**

**Матур кыз берлә вакты бик матур кичә хәзер ханның,**

**Матур кыз кичә, көндез дә кирәгенә хәзер ханның.**

**Сыйлый кыз һәм сөя, һәртөрле назлар күрсәтә ханга,**

**Сихерләнгән, тәмам гашыйк булып беткән Мәмәт ханда.**

**Бу кыз берлә көлеп уйнап, тәмам атна кадәр торгач,**

**Күңел ачкач, зәвыклангач вә күп рәхәт, сафа сөргәч,**

**Мәмәт хан кайта инде яшь бикә берлә Һиратына,**

**Ияртеп гаскәрен, саф-саф тезеп һәр дүрт җиһатына.**

Хәбәр китте Һиратка, алдан ук күп илчеләр чапты *(новость пошла в Герат, заранее уже много гонцов побежало)*,

Ки ягъни *(то есть; ки – что, который; ягъни – то есть)*: «Хан сәфәрдән бик сәламәт, сау, исән кайтты *(хан из путешествия здоровым, живым, невредимым вернулся)*!»

Халык каршыга килгән, барчасы бергә җыелганнар *(народ навстречу вышел, все вместе собрались)*,

Хатын-кызлар, балалар – җөмлә хан кайтышка килгәннәр *(женщины, дети – все к ханскому возвращению подошли)*.

Халык ханны сәламли; ханбикә баш селкә файтоннан *(народ хана приветствует; ханская жена головой кивает из фаэтона)*,

Яланаяк малайлар йөгерәләр файтон артыннан *(босоногие мальчишки бегут за фаэтоном)*.

Шулай барганда, аңсыздан Мәмәт хан бер кеше күрә *(так шествуя, неожиданно хан Мамат одного человека видит)*,

Тәгаҗҗеп берлә файтоннан торып карый аягүрә *(в изумлении в фаэтоне встав, смотрит, стоя на ногах)*.

Карап күрсә – йөзе нурлы бер ап-ак бүрекле карт *(посмотрев, видит – с сияющим лицом один в белоснежной шапке старик)*,

Җитен төсле сакалы ак, кыяфәтчә күрекле карт *(льну подобная борода белая, обликом красивый старец)*.

«Моны соң кайда күрдем *(его хоть где видел)*?» – уйлый торгач, ахыры, белде *(размышляя, наконец, вспомнил)*:

«Исәнме, и хәким бабай, кулың бир, монда кил, кил *(здравствуй, эй, мудрец-дед, руку давай, сюда иди, иди)*», – ди *(говорит)*.

**Хәбәр китте Һиратка, алдан ук күп илчеләр чапты,**
**Ки ягъни: «Хан сәфәрдән бик сәламәт, сау, исән кайтты!»**
**Халык каршыга килгән, барчасы бергә җыелганнар,**
**Хатын-кызлар, балалар – җөмлә хан кайтышка килгәннәр.**

**Халык ханны сәламли; ханбикә баш селкә файтоннан,**
**Яланаяк малайлар йөгерәләр файтон артыннан.**
**Шулай барганда, аңсыздан Мәмәт хан бер кеше күрә,**
**Тәгаҗҗеп берлә файтоннан торып карый аягүрә.**

**Карап күрсә – йөзе нурлы бер ап-ак бүрекле карт,**
**Җитен төсле сакалы ак, кыяфәтчә күрекле карт.**
**«Моны соң кайда күрдем?» – уйлый торгач, ахыры, белде:**
**«Исәнме, и хәким бабай, кулың бир, монда кил, кил», – ди.**

Хәким, ханга килеп *(мудрец к хану подойдя)*: «Йә хан, исәпне без өзик инде *(ну, хан, счет мы закроем уж; өзү – рвать, прервать)*,

Беләмсең вәгъдәбезне *(помнишь наш уговор)*? Син онытсаң, мин онытмыйм *(/если/ ты забудешь, я не забуду)*», – ди *(говорит)*.

«Олуг хан, вәгъдә бирдең син фәкыйранә теләгемне *(великий хан, обещание дал ты по /моему/ убогому желанию)*

Тәмам бирмәкче булдың бит бөтенләй үз теләгендәй *(всё отдать собирался ведь полностью по своему желанию)*.

Шулаймы *(так ведь)*? Бәс, шулай булса, биреп җибәр миңа кызны *(поэтому, раз так, отдай мне девушку; бирү – давать; җибәрү – отправлять)*,

Менә шул яшь бикәңне, ул йөзе ай, күзе йолдызы *(вот эту юную госпожу, ее лицо луна, глаза звезды)*!»

Хәкимнең сүзләреннән хан ниһаять тә гаҗәпләнде *(от слов мудреца хан, в конце концов, изумился)*:

«Ни сөйли карт пәри, бу әллә шашканмы гакылдан *(что говорит старый черт, или он сошел с ума)*. – ди *(говорит)*.

Ни булды, карт, сиңа, син әллә женләнден, саташтыңмы *(что случилось, старик, с тобой, или ты взбесился, бредишь)*?

Әтәч бирдем дигәч тә, әллә син хәтеңнән аштыңмы *(раз петуха дал, так ты из рамок вышел)*?

Дөрес, мин вәгъдә бирдем һәм бирәм, әйтмим дә: «Кит, бар!» – дип *(верно, я обещание дал и даю, не говорю же: «Иди, уходи!» – /так/ говоря)*.

Вәләкин син сора үлчәп, минем вәгъдәмгә чик бар бит *(но ты просьбу взвешивай, моему обещанию границы есть ведь)*.

**Хәким, ханга килеп: «Йә хан, исәпне без өзик инде,**
**Беләмсең вәгъдәбезне? Син онытсаң, мин онытмыйм», – ди.**
**«Олуг хан, вәгъдә бирдең син фәкыйранә теләгемне**
**Тәмам бирмәкче булдың бит бөтенләй үз теләгендәй.**

**Шулаймы? Бәс, шулай булса, биреп җибәр миңа кызны,**

**Менә шул яшь бикәңне, ул йөзе ай, күзе йолдызы!»**
**Хәкимнең сүзләреннән хан ниһаять тә гаҗәпләнде:**
**«Ни сөйли карт пәри, бу әллә шашканмы гакылдан. – ди.**

**Ни булды, карт, сиңа, син әллә җенләнден, саташтыңмы?**
**Әтәч бирдем дигәч тә, әллә син хәтеңнән аштыңмы?**
**Дөрес, мин вәгъдә бирдем һәм бирәм, әйтмим дә: «Кит, бар!» – дип.**
**Вәләкин син сора үлчәп, минем вәгъдәмгә чик бар бит.**

Кирәк булса, менә казнамнан ал пот-пот көмеш, алтын *(если нужно, вот из /моей/ казны бери пудами серебро, золото)*;
Сиңа булсын менә пар ат, көмеш көпчәкле бу файтон *(тебе /пусть/ будет вот пара лошадей, с серебряными колесами этот фаэтон)*.
Күзең туйганчы, һәртөрле читек-кәвеш, кызыл мал ал *(/пока/ глаза /не/ насытятся, всяческие сапоги-кявуши, красный товар бери; кәвеш – кявуши, национальная обувь)*!
Кирәк булса – вәзир бул яки ярты ханлыгымны ал *(если нужно – визирем будь или половину ханства бери)*!»

«Миңа һичнәрсә бирмә, тик бу ай йөзле кызыңны бир *(мне ничего не давай, только эту луноликую девушку дай)*!
Әгәр вәгъдәдә торсаң син, бу кыз, чулпан күзеңне бир *(если обещание держишь ты, эту девушку, звездные глаза дай)*!»
«Тфү! Чорт, карт пәри *(тьфу! Черт, старый бес)*!» – диде, бөтенләй кызды инде хан *(сказал, совсем закипел уже хан)*.
Мыек, сачны, сакалны да үрә торгызды инде хан *(усы, волосы, бороду заплетая, встал уже хан)*.

«Җитәр, күп шаулама, карт *(хватит, много не шуми, старик)*! Мин Мәмәт ханмын, беләмсең син *(я хан Мамат, знаешь ты)*?

Сиңа кыз нәрсәгә һәм нишлисең ул кыз белән соң син *(тебе девушка для чего, и что будешь делать с этой девушкой ты)*?

Алайса, мин сиңа, карт, инде һичбер нәрсә бирмим *(тогда я тебе, старик, уж совсем ничего не дам)*», – ди *(говорит)*.

«Югал күздән, икенче рәт сине алдымда күрмим *(исчезни с глаз, второй раз тебя перед собой не хочу видеть = не увижу)*», – ди *(говорит)*.

**Кирәк булса, менә казнамнан ал пот-пот көмеш, алтын;**
**Сиңа булсын менә пар ат, көмеш көпчәкле бу файтон.**
**Күзең туйганчы, һәртөрле читек-кәвеш, кызыл мал ал!**
**Кирәк булса – вәзир бул яки ярты ханлыгымны ал!»**

**«Миңа һичнәрсә бирмә, тик бу ай йөзле кызыңны бир!**
**Әгәр вәгъдәдә торсаң син, бу кыз, чулпан күзеңне бир!»**
**«Тфү! Чорт, карт пәри!» – диде, бөтенләй кызды инде хан.**
**Мыек, сачны, сакалны да үрә торгызды инде хан.**

**«Җитәр, күп шаулама, карт! Мин Мәмәт ханмын, беләмсең син?**
**Сиңа кыз нәрсәгә һәм нишлисең ул кыз белән соң син?**
**Алайса, мин сиңа, карт, инде һичбер нәрсә бирмим», – ди.**
**«Югал күздән, икенче рәт сине алдымда күрмим», – ди.**

«Тере чакта котыл да бак юлыңны, әйдә кач моннан *(пока жив спасайся и смотри /на свою/ дорогу, давай беги отсюда; юл – дорога)*,

Сөйләсәң күп, күрерсең күрмәгәнеңне палачымнан *(/если будешь/ говорить много, увидишь невиданное от /моего/ палача)*!»

Хәким картым тагын булган иде азрак талашмакчы *(мудрец-старик снова хотел ещё немного поспорить; талашу – ссориться)*

Мәмәт хан берлә: ник син бирмисең? – дип тарткалашмакчы *(с ханом Маматом: почему ты не даешь? – так поскандалить)*.

Утыртты картка хан бер зур тимер чукмар белән башка *(всадил = ударил старику хан одной большой железной булавой по голове)*,
Егылды карт, теге дөньяга китте бер дә кайтмаска *(упал старик, на тот свет ушел, чтобы не вернуться)*.
Һират шәһре шул ук хәлдә давыллап, җилләнеп китте *(в городе Герат в тот же момент ураган, ветер поднялся; давыллау – бушевать; җилләнү – ветренеть)*,
Кисәктән әллә нинди бер давыллы җил бәреп китте *(внезапно незнамо какой штормовой ветер ударил; бәрү – ударять; китү – здесь вспом. глагол, обозначает приобретение какого-либо качества в большей степени)*.

Менә шул хәлдә хан курыкты, төсе киткән, агарынган *(вот в таком положении хан испугался, его цвет ушел, побледнел)*,
Көлә кызы: ха-ха-ха! асла гөнаһтан куркмаганыннан *(смеется девушка: ха-ха-ха! потому что греха не боится; курку – бояться)*
Мәмәт ханның *(хана Мамата)*; тәгаҗҗеп берлә хан тиз әйләнеп карый *(в изумлении хан, быстро оглянувшись, смотрит)*
Матур кызга, эченнән куркса да, ыспайланып карый *(на красивую девушку, в душе /хоть/ и боится, прихорашиваясь, смотрит; ыспайлану – прихорашиваться)*.

**«Тере чакта котыл да бак юлыңны, әйдә кач моннан,**
**Сөйләсәң күп, күрерсең күрмәгәнеңне палачымнан!»**
**Хәким картым тагын булган иде азрак талашмакчы**
**Мәмәт хан берлә: ник син бирмисең? – дип тарткалашмакчы.**

**Утыртты картка хан бер зур тимер чукмар белән башка,**
**Егылды карт, теге дөньяга китте бер дә кайтмаска.**
**Һират шәһре шул ук хәлдә давыллап, җилләнеп китте,**
**Кисәктән әллә нинди бер давыллы җил бәреп китте.**

**Менә шул хәлдә хан курыкты, төсе киткән, агарынган,**
**Көлә кызы: ха-ха-ха! асла гөнаһтан куркмаганыннан**

**Мәмәт ханның; тәгаҗҗеп берлә хан тиз әйләнеп карый**

**Матур кызга, эченнән куркса да, ыспайланып карый.**

Озакламый шәһәрнең капкасыннан керделәр инде *(вскоре в городские ворота въехали уже; капка – ворота, калитка)*.

(Котылдылар усал карттан, аны үлтерделәр инде *(избавились от злого старика, его убили уже)*).

Менә алтын әтәч аңсызлан урыннан очы төште *(вот золотой петух неожиданно со /своего/ места слетел)*

Дә дәрхаль кунды файтонга *(и тут же осел в фаэтоне; куну – садиться, сесть /о птицах, насекомых/)*, куа хан: «Көш!» тә «Көш! Көш!» – ди *(гонит хан: «Кыш!» и «Кыш! Кыш!» – говорит)*.

Әтәч «прх! прх!» итеп ханның башы түбәсенә кунды *(петух «порх! порх!» делая = вспорхнув, на макушку ханской головы осел)*.

Канатын каккалап, ифрат ачы тавышлә кычкырды *(крыльями забив, весьма пронзительным голосом закричал)*.

Әтәч ханның башын гайрәтләнеп-гайрәтләнеп чукый *(петух ханскую голову, расхрабрившись, клюет)*,

Карап-карап халыкка, хан башыны «тук!» та «тук!» тукый *(поглядывая на народ, ханскую голову «тук» да «тук» долбит)*.

«Ни булган бу әтәчкә *(что случилось с этим петухом)*?!» – дип, халыкның котлары очты *(/так/ говоря, народ перепугался: “душа народа улетела”)*,

Кисәктән хан егылды, файтоныннан капланып төште *(внезапно хан упал, из фаэтона, опрокинувшись, выпал)*.

Егылгач, бер генә рәт «аһ» диде дә, үлде дәрхаль хан *(упав, один только раз «ах» сказал и тотчас же умер жан)*,

Халыкта тын да юк һич, тик тора бер җирдә, шаккаткан *(от народа ни вздоха нет совсем, тихо стоит на одном месте, пораженный)*.

Ә кыз шул хәл гомердә булмаган төсле гаип булды *(а девушка в то же время, как в жизни не существовавшая, исчезла)*,
Карыйлар – бу әтәч кайда *(смотрят – этот петух где)*? Әтәч тә бергә юк булды *(и петух вместе исчез: «нет стало»)*.

Бу ялган инде, әлбәттә, шулай да языла шул бу *(это выдумка уж, конечно, но и так пишется уж это)*,
Сабыйлар күңленә аз-аз уку дәрте сала шул бу *(в детской душе понемногу читательский азарт вызывает уж это)*.

**Озакламый шәһәрнең капкасыннан керделәр инде.**
**(Котылдылар усал карттан, аны үлтерделәр инде).**
**Менә алтын әтәч аңсызлан урыннан очы төште**
**Дә дәрхаль *(=шунда ук)* кунды файтонга, куа хан: «Көш!» тә «Көш! Көш!» – ди.**

**Әтәч «прх! прх!» итеп ханның башы түбәсенә кунды.**
**Канатын каккалап, ифрат ачы тавышлә кычкырды.**
**Әтәч ханның башын гайрәтләнеп-гайрәтләнеп чукый,**
**Карап-карап халыкка, хан башыны «тук!» та «тук!» тукый.**

**«Ни булган бу әтәчкә?!» – дип, халыкның котлары очты,**
**Кисәктән хан егылды, файтоныннан капланып төште.**
**Егылгач, бер генә рәт «аһ» диде дә, үлде дәрхаль хан,**
**Халыкта тын да юк һич, тик тора бер җирдә, шаккаткан.**

Ә кыз шул хәл гомердә булмаган төсле гаип булды,
Карыйлар – бу әтәч кайда? Әтәч тә бергә юк булды.

Бу ялган инде, әлбәттә, шулай да языла шул бу,
Сабыйлар күңленә аз-аз уку дәрте сала шул бу.

1908.

**ЯПОН ХИКӘЯСЕ *(японский рассказ)*.**

(Буренинннан *(по Буренину)*)

Электә бер Ташчы торган бу дөньяда *(в прошлом один каменотес жил в этом мире)*,
Безнең җирдә түгел – ерак Япониядә *(не в нашей местности – в далекой Японии)*;

Үзе булган таза гына бер яшь кеше *(сам был здоровый такой молодой человек)*,
Ялыкмыйча эшли икән ул таш эше *(не утомляясь, работает он, оказывается, с камнями: «каменную работу»; ялыгу – утомляться)*.

Ризыкланган ачы тирләр һәм көч белән *(питался горьким потом и силой)*,
Көн буена ташлар ватып чүкеч белән *(целыми днями камни разбивая молотком)*;

Булганлыктан һаман да эш, һаман да эш *(/из-за того, что/ была все работа да работа)*,
Күралмаган бу яшь егет рәхәт тормыш *(не видел: “не мог видеть” этот молодой парень хорошей жизни; күрү – видеть; алу – мочь)*.

Беркөн шулай эшләп-эшләп каты аргач *(в один день так /много/ работав и сильно устав; ару – уставать)*
Күңле кайткан эштән тәмам хәлдән тайгач *(настроение упало, /когда/ от работы порядком силы потерял; күңел – душа, настроение; кайту – убывать, спасть; таю – перен. терять)*

Тотынган ул үз-үзенә тарланырга *(принялся он сам себе сетовать)*,
Мондый начар көн күрмештән зарланырга *(/на то, что/ такой плохой день видит, жаловаться)*:

«Ходаем, ник фәкыйрь иттең мине болай *(Боже /мой/, почему бедным сделал меня таким)*?
Рәхмәтең киң, мин бәндәңне кылсаң да бай *(милость /твоя/ широка, /если/ меня, /своего/ раба сделаешь богачом; бәндә – человек, рел. раб)*;

Бүтәннәрдәй мин дә рәхәт сөрер идем *(как другие, и я блаженствовал бы; сөрү – гнать; здесь употребляется как часть словосочетания, рәхәт сөрү – наслаждаться, блаженствовать)*,
Тынычлык һәм бәхет йөзен күрер идем *(спокойствие и счастье увидел бы; йөз – лицо, лицевая сторона)*».

**Электә бер Ташчы торган бу дөньяда,**
**Безнең җирдә түгел – ерак Япониядә;**

**Үзе булган таза гына бер яшь кеше,**
**Ялыкмыйча эшли икән ул таш эше.**

**Ризыкланган ачы тирләр һәм көч белән,**
**Көн буена ташлар ватып чүкеч белән;**

**Булганлыктан һаман да эш, һаман да эш,**
**Күралмаган бу яшь егет рәхәт тормыш.**

**Беркөн шулай эшләп-эшләп каты аргач**
**Күңле кайткан эштән тәмам хәлдән тайгач**

**Тотынган ул үз-үзенә тарланырга,**

**Мондый начар көн күрмештән зарланырга:**

**«Ходаем, ник фәкыйрь иттең мине болай?**
**Рәхмәтең киң, мин бәндәңне кылсаң да бай;**

**Бүтәннәрдәй мин дә рәхәт сөрер идем,**
**Тынычлык һәм бәхет йөзен күрер идем».**

Шуннан гына очып үткән бер Фәрештә *(сразу после этого пролетал один Ангел; очу – летать; үтү – миновать)*
Әллә ничек моның моңын, зарын иштә *(не знаю как его грусть, жалобу слышит; моң – грусть; зар – жалоба, ропот)*.

Һәм әйтә ул *(и говорит он)*: «Ярар, яхшы, шулай бул *(ладно, хорошо, таким будь)*», – ди *(говорит)*,
Ягъни: «Үзең теләгәнеңчә бай бул», – ди *(то есть: «По своему желанию богатым будь», – говорит)*.

Безнең Ташчы шул минуттук зур бай булды *(наш Каменотес в ту же минуту большим богачом стал)*,
Азапланган читен тормыш уңай булды *(мучительная, тяжелая жизнь комфортной стала)*;

Инде хәзер авыр эшләр муенда юк *(уже сейчас трудных дел на шее нет)*,
Рәхәт ята, һичбер нәрсә уенда юк *(блаженно лежит, совсем ничего в мыслях нет)*.

Шул вакытта ташчы күрә: зур урамнан *(в это время каменотес видит: по большой улице)*
Үтеп бара гаскәр берлән олуг бер хан *(проходит с армией великий один хан)*.

Киемнәре, баш өстендә чатырлары *(одежда /его/, на голове корона /его/; чатыр – шатер)*

Ялт-йолт килә көнгә каршы – алтын бары *(сверкает ярче дневного света: “вопреки дню” – золотое всё)*.

Ташчы әйтә: «Зур эшмени бу, бай булу *(Каменотес говорит: “Большое ли дело это, богачом быть)*?

Насыйп булса менә шушындый хан булу *(если суждено вот таким ханом быть)*, –

Булыр иде шул вакытта бәхтем минем *(было бы в такое время счастье мое)*;

Аһ, булсачы вәзирләрем, тәхтем минем *(ах, были бы /у меня/ визири, корона моя”)*!»

**Шуннан гына очып үткән бер Фәрештә**
**Әллә ничек моның моңын, зарын иштә.**

**Һәм әйтә ул: «Ярар, яхшы, шулай бул», – ди,**
**Ягъни: «Үзең теләгәнеңчә бай бул», – ди.**

**Безнең Ташчы шул минуттук зур бай булды,**
**Азапланган читен тормыш уңай булды;**

**Инде хәзер авыр эшләр муенда юк,**
**Рәхәт ята, һичбер нәрсә уенда юк.**

**Шул вакытта ташчы күрә: зур урамнан**
**Үтеп бара гаскәр берлән олуг бер хан.**

**Киемнәре, баш өстендә чатырлары**
**Ялт-йолт килә көнгә каршы – алтын бары.**

**Ташчы әйтә: «Зур эшмени бу, бай булу?**
**Насыйп булса менә шушындый хан булу, –**

**Булыр иде шул вакытта бәхтем минем;**
**Аһ, булсачы вәзирләрем, тәхтем минем!»**

Тагы шуннан очып барган шул Фәрештә *(снова там пролетал тот Ангел)*
Бу Ташчының сөйләгәне сүзен иштә *(он Каменотесом сказанные слова услышал)*:

«Теләгәнең булса синең, син хан бул», – ди *(/если это/ желаемое есть твое, ты ханом будь)*,
Үзе китә очып: «Хәзергә сау бул!» – ди *(сам улетает: «А сейчас до свидания!» – говорит)*.

Ташчы карый: шул ук хәлдә ул хан булган *(Каменотес смотрит: в тот же момент он ханом стал)*,
Һәр ягына вәзирләр һәм гаскәр тулган *(с каждой стороны визирей и армии полно)*.

Уенчылар матур көйләр көйләгәли *(музыканты красивые мелодии наигрывают)*,
Баш өстендә алтын зонтик күләгәли *(над головой золотой зонтик тень дает)*.

Шулай да бик рәхәт түгел: кояш эссе *(и так не очень хорошо: солнце жаркое)*,
Гаҗиз калды хан эсседән, тәмам пеште *(бессильным стал хан от жары, порядком упарился)*;

«Кирәк түгел, – ди, – хан булу һәм баш булу *(не нужно, – говорит, – ханом быть и главой быть)*,
Насыйп булса икән миңа кояш булу *(если бы суждено было мне солнцем быть)*!»

Шул Фәрештә тагын шунда җитеп килеп *(тот Ангел снова туда подлетев; җитү – достичь)*,
Китте очып: «Ярар, булсын синеңчә», – дип *(улетел: «Ладно, /пусть/ будет по-твоему», – сказав)*.

Шул минутта ташчы егет кояш булып *(в ту же минуту парень-каменотес солнцем став)*,
Күктә тора бу дөньяга нурлар коеп *(в небе держится, на этот мир лучи рассыпая)*.

**Тагы шуннан очып барган шул Фәрештә**
**Бу Ташчының сөйләгәне сүзен иштә:**

**«Теләгәнең булса синең, син хан бул», – ди,**
**Үзе китә очып: «Хәзергә сау бул!» – ди.**

**Ташчы карый: шул ук хәлдә ул хан булган,**
**Һәр ягына вәзирләр һәм гаскәр тулган.**

**Уенчылар матур көйләр көйләгәли,**
**Баш өстендә алтын зонтик күләгәли.**

**Шулай да бик рәхәт түгел: кояш эссе,**
**Гаҗиз калды хан эсседән, тәмам пеште;**

**«Кирәк түгел, – ди, – хан булу һәм баш булу,**
**Насыйп булса икән миңа кояш булу!»**

**Шул Фәрештә тагын шунда җитеп килеп,**
**Китте очып: «Ярар, булсын синеңчә», – дип.**

**Шул минутта ташчы егет кояш булып,**

**Күктә тора бу дөньяга нурлар коеп.**

Бераздан соң әллә кайдан чыга болыт *(через некоторое время не знаю откуда выходит туча)*,

Җир һәм кояш арасына пәрдә булып *(между землей и солнцем занавесом став)*,

Каплап тора әллә нинди гайрәт берлә *(закрывает незнамо с какой силой; каплау – закрывать; тору – здесь вспом. глагол, обозначает длительность действия)*,

Күренмидер кояшка җир, кояш – җиргә *(не видна солнцу земля, солнце – земле)*.

Егет әйтә: «Кирәк түгел кояш булу *(парень говорит: "Не нужно солнцем быть)*,

Болыттан да кимсеттереп, юаш булу *(и тучей быть униженным, покорным быть; кимсетү – оскорблять, унижать)*.

Тәңрем, ирек бир син миңа, болыт булыйм *(Боже /мой/, свободу дай ты мне, тучей /пусть/ буду)*,

Болыт булып, җиһанга баш булып торыйм *(тучей став, миру главой пусть буду")*».

Фәрештә дә шул вакытта җитеп килеп *(и Ангел, в это время подлетев)*,

Китә күккә: «Ярар, булсын синеңчә», – дип *(улетает в небо: «Ладно, /пусть/ будет по-твоему», – сказав)*.

Шул ук вакыт Ташчы егет болыт була *(в то же время парень-каменотес тучей становится)*,

Җир йөзенә яңгырларын коеп тора *(на поверхность земли дожди проливает)*.

Чиләк-чиләк булып яңгыр яуганыннан *(/от того, что/ ведрами-ведрами дождь лился)*,

Сулар артып, ташып чыкты ярларыннын *(воды прибавившись, разлившись, вышли из берегов; яр – берег)*,

Сахра, болын, игенлекләрне су басты *(землю, луга, поля вода затопила)*,
Һәрнәрсәгә урын булды дулкын асты *(всему место оказалось под волной)*.

**Бераздан соң эллэ кайдан чыга болыт,**
**Җир һәм кояш арасына пәрдә булып,**

**Каплап тора әллә нинди гайрәт берлә,**
**Күренмидер кояшка җир, кояш – җиргә.**

**Егет әйтә: «Кирәк түгел кояш булу,**
**Болыттан да кимсеттереп, юаш булу.**

**Тәңрем, ирек бир син миңа, болыт булыйм,**
**Болыт булып, җиһанга баш булып торыйм».**

**Фәрештә дә шул вакытта житеп килеп,**
**Китә күккә: «Ярар, булсын синеңчә», – дип.**

**Шул ук вакыт Ташчы егет болыт була,**
**Җир йөзенә яңгырларын коеп тора.**

**Чиләк-чиләк булып яңгыр яуганыннан,**
**Сулар артып, ташып чыкты ярларыннын,**

**Сахра, болын, игенлекләрне су басты,**
**Һәрнәрсәгә урын булды дулкын асты.**

Бу дулкыннар кубарса да шау-шу, гауга *(эти волны /хоть/ и подняли шум, гам)*,

Һөҗүм итеп килсәләр дә, охшап яуга *(нападая, /хоть/ и пришли, подобно врагу; яу – враг, неприятель)*, –

Шунда үсеп тора торган олуг таш-тау *(там растущая огромная скала; тору – здесь вспом. глагол, обозначает длительность действия)*
Зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау *(с пылинку вреда не получив, осталась невредимой; зәррә = тузан – пыль)*.

Егет әйтә: «Кирәк түгел болыт булу *(парень говорит: "Не нужно тучей быть)*,
Артык миңа, болыт булганчы, юк булу *(больше мне, чем тучей быть, ничем быть)*;

Гайрәтемнән күрсәтмичә һичбер какшау *(от /моей/ мощи не выказывая никакого колебания)*,
Минем көчтән көлеп тора шушы таш-тау *(над моей силой смеется эта скала")*!»

Шунда тагын фәрештәсе килеп җитә *(там снова /его/ ангел прилетел)*:
«Ярар, яхшы, шулай бул син», – диеп китә *(«ладно, хорошо, таким будь ты», – сказав, улетает)*.

Ташчы егет шул ук минут була таш-тау *(парень-каменотес в ту же минуту стает скалой)*;
«Гомерлеккә торырмын, – ди, – мин шунда сау *(вечно буду стоять, – говорит, – я здесь невредимым)*».

Һәрьяклардан килсәләр дә сулар ташып *(со всех сторон /хоть/ и придут воды, разлившись)*,
Дулкыннары бәрелсәләр дә шып та шып *(волны /если будут/ биться круто, внезапно)*!

Кибаранә күтәреп баш, безнең таш-тау *(гордо подняв голову, наша скала)*

Селкенми дә, кузгалмый да тора сап-сау *(не шелохнется, не шевельнется, стоит цела-невредима)*.

**Бу дулкыннар кубарса да шау-шу, гауга,**
**Һөҗүм итеп килсәләр дә, охшап яуга, –**

**Шунда үсеп тора торган олуг таш-тау**
**Зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау.**

**Егет әйтә: «Кирәк түгел болыт булу,**
**Артык миңа, болыт булганчы, юк булу;**

**Гайрәтемнән күрсәтмичә һичбер какшау,**
**Минем көчтән көлеп тора шушы таш-тау!»**

**Шунда тагын фәрештәсе килеп җитә:**
**«Ярар, яхшы, шулай бул син», – диеп китә.**

**Ташчы егет шул ук минут була таш-тау;**
**«Гомерлеккә торырмын, – ди, – мин шунда сау».**

**Һәрьяклардан килсәләр дә сулар ташып,**
**Дулкыннары бәрелсәләр дә шып та шып!**

**Кибаранә күтәреп баш, безнең таш-тау**
**Селкенми дә, кузгалмый да тора сап-сау.**

Шул вакытта әллә кайдан чыга инсан *(в это время не известно откуда выходит человек)*,
Кулларына балта берлән чүкеч тоткан *(в руку топор и молоток взял)*.

Килә дә ул, бу таш-тауны вата башлый *(подходит он и эту скалу разбивать начинает)*,

Таш артыннан ташны ватып ата башлый *(камень за камнем откалывая, бросать начинает)*.

Егет әйтә: «Мин күп нәрсә булып үттем *(парень говорит: "Я много кем побывал)*,

Һәрберсеннән галилек һәм бәхет көттем *(от каждого /состояния/ величие и счастье ждал)*;

Күрдем хәзер: эшкә һичнәрсә тиң түгел *(увидел сейчас: работе ничего равного нет)*,

Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел *(работы сильнее что-то найти невозможно)*.

Кирәк түгел, мин яңадан Ташчы булам *(не нужно, я снова Каменотесом буду)*,

Әүвәлгечә иҗтиһатлы булам *(как раньше, старательным буду")*».

Кодрәт берлә шунда егет ташчы була *(с усилием там парень каменотесом становится)*,

Әүвәлгечә иҗтиһатлы эшче була *(как раньше старательным работником становится)*.

**Шул вакытта әллә кайдан чыга инсан,**

**Кулларына балта берлән чүкеч тоткан.**

**Килә дә ул, бу таш-тауны вата башлый,**

**Таш артыннан ташны ватып ата башлый.**

**Егет әйтә: «Мин күп нәрсә булып үттем,**

**Һәрберсеннән галилек һәм бәхет көттем;**

**Күрдем хәзер: эшкә һичнәрсә тиң түгел,**

**Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел.**

**Кирәк түгел, мин яңадан Ташчы булам,**

**Әүвәлгечә иҗтиһатлы булам».**

**Кодрәт берлә шунда егет ташчы була,**

**Әүвәлгечә иҗтиһатлы эшче була.**

1909.